«76 нчы «Җилкәй» катнаш балалар бакчасы»
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

«Раслана»
Педагогик совет белән
Протокол 31.08.2022 № _____

«Кертелә»
Боерык белән 31.08.2022 № 210
Мөдир ________ Т. В. Мартьянова

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА**
по реализации основной общеобразовательной программы
дошкольного образовательного учреждения
на 2022 - 2023учебный год
средняя группа № 9(4-5 лет)

**УКЫТУ-ЭШ ПРОГРАММАСЫ**
2022 -2023 нче уку елына мәктәпкәчә белем бирү
учреждениясенең төп бердәм укыту программасын тормышка ашыру
9 нчы уртанчылар төркеме (4 -5 яшь)

Тәрбиячеләр: Хасанова Лилия Миннивасильовна
беренче квалификцион категория
Хуснутдинова Лилия Фарисовна
беренче квалификцион категория

Яр Чаллы шәһәре

**Эчтәлек**

**1.Максатчан бүлек**........................................................................................................... 2

1.1 Аңлатма язуы ………………………………………………………. ..............................
2
1.2 Программаның төп бурычлары:............................................................................. 3
1.3 Тәрбия һәм белем бирү процессының эчтәлеге..................................................... 4
1.4 Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы турында гомуми мәгълүмат......................................... 5
1.5 Төркемдә тәрбияләнүче балалар турында белешмә .............................................................. 5
1.6 Төркемдә тәрбияләнүче балаларның гаиләләре турында белешмә....................................... 6
1.7 Балалар психик үсешенең яшь үзенчәлекләре......................................................................... 6
1.8 Балаларның гомуми белем бирү программасын үзләштерүдә планлаштырылган нәтиҗәләр........................................................................................................... 7

***II*. *Эчтәлек бүлеге***

2.1 Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге........................................................................... 8
2.2 4-5 яшьлек балалар белән эшне комплекслы-тематик планлаштыру............................. 16
2.3 Ата-аналар белән эшләүнең төп бурычлары................................................................ 19

**III. Оештыру бүлеге**

3.1 Төркемнең рухи үсеш мохите һәм материаль яктан тәэмин ителүе.............................. 20
3.2. Методик яктан тәэмин ителүе............................................................................... 21
3.3 Уртанчылар төркемендә көндәлек режим............................................................... 23
3.4 Белем бирү эшчәнлеге челтәре............................................................................. 24
3.5 Программа үтәлешен йомгаклау нәтиҗәләре........................................................... 24

***IV.* Кушымта**

4.1. Балалар бакчасында балаларны сәламәтләндерү эше.............................................. 26
4.2 Уяну гимнастикасы буенча комплекс – тематик план................................................ 27
4.3 Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча комплекс - тематик план.................................... 29

## *I. Эш программасының максатчан бүлеге*

### *1.1 Аңлатма язуы.*

Әлеге эш программасы Н.Е.Веракса, Т.С. Комарова, М. А. Васильевалар тарафыннан ФГОС буенча **“Туганнан алып мәктәпкә кадәр”** программасына таянып төзелә. Хәзерге вакытта мәктәпкәчә белем бирү системасында күп кенә мәсьәләләргә яңача караш таләп итә торган шактый җитди вакыйгалар булды. Яшәешнең бүгенге таләпләре һәм мәгълүмати җәмгыятьнең тиз темплар белән формалашуы мәгариф системасы алдында яшь буынга белем бирү максатын һәм бурычларын, форма һәм эчтәлеген тамырыннан үзгәртү мәсьәләсен куйды. Россия педагоглары, заман таләпләрен искә алып, беренче мәртәбә буларак, бала шәхесе үсешен – белем бирүнең мәгънәсе һәм максаты дигән фикергә килделәр. Мәгариф системасындагы яңалыкларны тормышка ашыру өчен бакча балаларына белем-тәрбия бирүдә яңа федераль дәүләт таләпләре куелса, шуның дәвамчысы буларак үсеп килүче буынга белем һәм тәрбия бирүнең икенче буын дәүләт стандартлары (ФДББС) төзелде. ФДББС - гомуми белем бирү программасын тормышка ашыруда кирәк булган нормаларны билгели. Һәм ул балалар бакчаларының төп документы булып тора. Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандартлары 2014 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керде. Яңа Закон нигезендә, мәктәпкәчә белем бирү баскычында тәрбия һәм белем бирү эшчәнлеге федераль дәүләт стандартлары таләпләре буенча оештырыла. Белем бирү программасының эчтәлеге 5 белем өлкәсен алырга тиеш: социаль-коммуникатив үсеш; танып белү үсеше; сөйләм үстерү; сәнгати - эстетик үсеш һәм физик үсеш. Ләкин белем бирү өлкәләрен үзләштерү гомумән кабул ителгән педагогик принципларга нигезләнә. Эшчәнлек конспектлары, үстерешле белем бирү, белем бирү барышында тәрбияләү, фәннилек, эзлеклелек һәм системалылык, аңлаешлылык, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә ала. Физик үсеш балалар бакчасының өстенлекле юнәлеш эшчәнлегендә- **балаларның терәк-хәрәкәттә булган кимчелекләрен квалификацияле төзәтмәләр кертү юнәлешендә алып барыла.**

Безнең балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала, сөйләм сыйфаты, төрлелеге белән аерылып тора. Эшчәнлек төрләрен оештыру федераль дәүләт таләпләрендә каралган интегратив сыйфатлар формалаштыруга: физик яктан үсеш алган, төп культура-гигиена күнекмәләрен үзләштергән; кызыксынучан, актив; интеллектуаль һәм шәхси бурычларны чишә, кеше хәленә керә белүчән, эмоциональ; өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашу ысулларын, чараларын үзләштергән; үзе, гаиләсе, әйләнә-тирәсе, дәүләт, дөнья, табигать турында беренчел күзаллауларга ия булган; элементар гомумән кабул ителгән нормаларны, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үзләштергән; беренчел кыйммәткә ия булган күзаллаулар нигезендә үзенең тәртибе белән идарә итүгә һәм үз гамәлләрен планлаштыруга сәләтле; өйрәтү эшчәнлегенең универсаль нигезләрен үзләштергән бала шәхесе тәрбияләүгә юнәлдерелә. Тәрбиячеләр иң беренче, баланы шәхес итеп тәрбияләргә, аның индивидуаль үзенчәлекләрен искә алырга, кызыксынучанлык, иҗади фикерләү дәрәҗәсен үстерергә, акыл хезмәте өчен кирәкле шартлар, мохит тудырырга, яңа күнекмәләр бирергә, эшкә өйрәтергә тиеш. Аннан соң гына балаларга белем бирү өстендә эшләргә дигән аңлатмалар тора. Бу исә мәктәпкәчә яшьтәге балаларны үзенчәлекле эш төрләрендә (иң беренче чиратта – уен вакытында) һәрьяклап үстерергә, ә үсеш дәрәҗәсе сыйфатлы булырга һәм баланың киләчәктә уңышлы урта белем алуына алшартлар тудырырга тиеш. Шул ук вакытта Стандартлар нигезендә ятучы принциплар мәктәпкәчә белем бирүнең вариативлыгын күздә тоталар һәм, баланың шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып, аның үсешен тәэмин итәләр.

Бу:

- Балачакның күптөрлелеген булдыру; кешенең гомуми үсешендәге мөһим чор буларак балачакның уникальлеген һәм үзкыйммәтен саклау. Балачак үзеннән-үзе аерым мөһим мәгънәгә ия. Федераль дәүләт мәктәпкәчә белем бирү стандартлары буенча, баланың үз тормышындагы киләчәк бер чорына әзерлеге түгел, ә нәкъ менә хәзерге вакыттагы торышы, бүгенгесе әһәмиятле.

- Өлкәннәрнең (әти-әниләр, тәрбиячеләр) балалар белән үзара бәйләнеше, мөнәсәбәте шәхси үсеш һәм гуманлык характерын йөртә.
- Бала шәхесенә ихтирам.
- Программа балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, иң беренче чиратта уен формасында, иҗади активлыкта, танып белү, эзләнү эшчәнлегендә тормышка ашырыла, баланың нәфис-нәфасәти үсешен тәэмин итә.
ФДББС буенча төркемнең предметлы үсеш мохите 7 принциптан тора:
- бай эчтәлекле
- төрләндерү
- үзгәртү
- полифункциональ
- вариатив
- ирекле алу
- куркынычсызлык (иминлек)

Төркемдә оештырылган предметлы-үстерелешле мохит балаларда шатлык хисе, балалар бакчасына карата эмоциональ уңай караш, бакчага йөрү теләген арттыра, яңа белемнәр тупларга ярдәм итә, танып-белүләрен, актив иҗади сәләтләрен үстерә. Гомуми белем бирү федераль дәүләт стандартларының башка баскычларында мондый принциплар юк.

***1.2 Программаның төп бурычлары:***

- Һәр баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында төрле яклы үсеш алуы турында кайгырту.
- Балаларны аралашучан, игелекле, кызыксынучан, инициативлы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерү максатыннан чыгып, төркемнәрдә кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек атмосферасы тудыру.
- Балалар эшчәнлеген төрле төрләрен киң куллану, укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан аларны интегральләштерү.
- Тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештыру.
- Балаларның мөмкин булганча төрле эшчәнлекләрен файдалану, белем бирү процессын нәтиҗәлерәк итү максатында аларны берләштерү.
- Мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү оешмасы һәм гаилә шартларында бала тәрбиясенә якын килүгә юнәлеш бирү.
- Гаиләнең балалар бакчасы төркемнәре һәм мәктәпкәчә оешманың тормышында катнашуын тәэмин итү.

Балалар бакчасында бу эш программасы һәр баланың шәхси үзенчәлекләрен һәм мөмкинлекләрен, шул исәптән, балаларның сәламәтлекләрен саклау максатыннан, милли-региональ компонентлар, **УМК** кулланып эшләүне дә исәпкә алып төзелә. Мәктәпкәчә яштәге балаларга ана телен өйрәтү аларның билгеле бер күләмдә сүз байлыгын булдырудан башлана.

Бирелгән якынча сүзләр исемлеге тәрбиячегә квартал саен яки ел ахырында балаларның ана телен яхшылап өйрнү һәм сөйләм телен үстерү өчен ярдәм итәчәк. Аваз культурасының төзелешен өйрәткәндә төп игътибар авазларны ишетә һәм аера, аларны дөрес итеп әйтә белү күнекмәләре булдыруга ярдәм итә. Грамматик конструкцияләр, сөйләм үрнәкләре, балаларның яшь үзенчәлекләрен, мөмкинлекләрен, хәзерлек дәрәҗәләрен исәпкә алып тәкъдим ителә. Балаларда аеруча тартым конструкциясе, төшем килешендәге исемнәрне куллану зур кыенлык тудыра Шунлыктан бу материалны өйрәнүгә тәрбияче җитди игътибар итәргә тиеш. Аларны активлаштыру һәм ныгытуга да вакыт күбрәк бирергә кирәк. Программа ел фасылларына яки сөйләм эчтәлегенә бәйле булган табышмаклар, мәкаль, әйтемнәр белән танышуны, әкиятләр укуны, җырлар өйрәнүне, рәсемнәр буенча сөйләүне, милли мәдәният белән таныштыруны, дидактик уеннар уйнауны да күздә тота. Билгеле булганча, балалар тормышында уен зур урын алып тора. Шуңа күрә программада балаларның ана телендә алган белемнәрен һәм күнекмәләрен ныгыту өчен күп төрле уеннар (сүзле, дидактик, сюжетлы, рольле, хәрәкәтле, һ.б.) тәкъдим ителә

Укыту-методик комплектында ФГОС күрсәткән өч белем бирү өлкәсе карала:
- **“Танып белү”** белем бирү өлкәсе табигать, аның үзенчәлекләре, экологик бәйләнешләр белән таныштыру; балаларның ел фасыллары турындагы белемнәрен тирәнәйтү, системалаштыру; нәниләрдә экология бурычларын гамәлгә ашыруны, туган як, өлкәннәр хезмәте турында балаларның белемнәр тирәнәйтүне максат итеп куя.
- **“Аралашу”** белем бирү өлкәсе нәниләрдә туган телгә мәхәббәт, матур әдәбият әсәрләре белән кызыксыну, авазларны дөрес әйтү, бәйләнешле сөйләм культурасы булдыруга, сабыйларга кара-каршы сөйләшә белү (диалогик сөйләм) күнекмәләрен камилләштерү,сәнгатьле сөйләм чараларын үзләштерүгә булышлык итү бурычларын гамәлгә ашыра.
- **“Матур әдәбият”** белем бирү өлкәсе кешеләрне һәрчак яхшыга гына өндәүче, акыллы, тапкыр булырга киңәш бирүче, авыр вакытта югалып калмаска, нык ихтыярлы, батыр йөрәкле булырга өйрәтүче, яшь үзенчәлекләрен искә алып сайланган шигырьләр, хикәяләр, әкиятләрбелән танышуны, балаларны әдәби телдә сөйләшергә өйрәтүне максат итеп куя.

Укыту-методик комплектында тупланган материал шулай ук балаларның сөйләмен үстерү, тирә -юнь, матур әдәбият әсәрләре белән таныштыру максатында рәсем ясау, әвәләү, конструкцияләү, кисеп ябыштыру, музыка, физкультура эшчәнлекләрендә, иртән балаларны кабул итү, саф һавада булу, табигатьне күзәтү вакытында, әти-әниләр белән бердәм эшчәнлектә кулланыла һәм ныгытыла.

Әлеге бурычларга ирешү эшчәнлекнең төрле вакытларында алып барыла:
- Белем бирү эшчәнлеге (уен, аралашу, хезмәт, сәнгати – эстетик үсеш, тәрбия эш планы)
- Балаларның көндәлек эшчәнлеге;
- Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге;
- Программаны тормышка ашыру максатыннан ата - аналар белән даими эш.

Программа тарафыннан кулланган бурычларны тормышка ашыру белем бирү эшчәнлеге вакытында гына түгел, ә әлеге балалар бакчасы эчендәге үзенчәлекләргә таянып төзелгән көндәлек эшчәнлек вакытында да алып барыла.

Шунысына төшенү мөһим: стандартлар мәктәпкәчә яшьтәге бөтен балаларны да бер калыпка салып үлчәү өчен эшләнмәгән. Тәрбиячеләр, иң беренче чиратта, балаларга индивидуаль якын килеп, шәхес буларак карарга тиешләр. Катгыйлык һәм дисциплинадан нәниләрнең шәхси психологик һәм физиологик үзенчәлекләре искә алып, күңелләрен күтәрү, үзара уңай мөнәсәбәт булдыруга күчү зарур.

Тәрбияләнүче һәр баланың мөмкинлекләрен һәм ихтыяҗларын истә тотып, аларның шәхес буларак үсүенә һәм формалашуына ярдәм итү. Нәниләрнең бакчада үткән һәр көнен мавыктыргыч шөгыльләр, яңадан-яңа уеннар, идеяләр белән баету өстендә эш алып бару, беркемне дә читтә калдырмыйча, эшчәнлеккә җәлеп итү. Балаларның мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү һәм активлыгын арттыру – тәрбияче буларак төп бурычларым. Программаның вакыты бер ел ( 2022 – 2023) уку елы өчен.

### *1.3 Тәрбия һәм белем бирү процессының эчтәлеге*

Бүгенге мәктәпкәчә мәгарифнең приоритетлары үзгәрү сәбәпле балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программаларын яңартырга кирәк булды. Мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учрежденияләре хезмәткәрләре, яңа заман таләпләрен исәпкә алып, башка концептуаль нигезендә төзелгән программалардагы мәсьәләләрне һәм эчтәлекне әлеге документка мөстәкыйль рәвештә кертәләр. Шулардан чыгып, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбия һәм белем процессында “Физик үсеш”, “Социаль - коммуникатив үсеш”, “Танып белү”, “Сөйләм үстерү”, “Нәфис-нәфасәти үсеш” юнәлешләре булуы мөһим. Эш программасның эчтәлеге яшь үзенчәлекләрен күздә тотып, балага тәрбия һәм белем бирүдә юнәлтелгән эшчәнлек төрләрен үз эченә ала.

Программа уртанчылар төркеме өчен, 4 яшьтән 5 яшькә кадәрге чор. Программа тәрбия һәм белем бирү үсешенең барлык төп юнәлешләрен чагылдыра.

***1.4 Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы турында гомуми мәгълүмат***

Төркемнең эшчәнлеге «76 нчы «Җилкәй» катнаш балалар бакчасының» төп белем бирү Программасының үтәлешенә юнәлгән һәм түбәндәге документларга нигезләнә:

<u>Федераль дәрәҗәдә:</u>

• Федеральный закон «Закон об Образовании » от 29.12.2012 г. N 273-ФЗ
• Закон РТ «Закон об Образовании »;
• Методические рекомендации Минобрнауки «О разработке основной общеобразовательной программы дошкольного образования» от 21 октября 2010 года, № 03-248.
• Санитарно-эпидемиологические требования к устройству, содержанию и организации режима дошкольных образовательных учреждений (СанПиН 2.4.1.3049-13);

<u>Региональ дәрәҗәдә:</u>

•Приказ Министерства образования и науки РТ от 17.11.2010 СЭД- 26-01-21-164 «О разработке основной общеобразовательной программы дошкольного образования»;

<u>Җирле дәрәҗәдә:</u>

• Устав муниципального бюджетного дошкольного образовательного учреждения «Детский сад комбинированного вида №76 “Ветерок” утвержден постановлением Руководителя ИК.

• Приказ МБДОУ «Детский сад № 76 «Ветерок » «О разработке примерной основной общеобразовательной программы дошкольного образования МБДОУ «Детский сад № 76 «Ветерок».
• План работы МБДОУ «Детский сад № 76 «Ветерок» на 2016 -2017 учебный год.
• Основная образовательная программа МБДОУ «Детский сад № 76 «Ветерок»

Төркемдә белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге түбәндәге программаларга һәм методик әсбапларга таянып төзелгән:

- Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү Программасы "От рождения до школы»(под редакцией Н.Е.Веракса, Т.С.Комаровой, М.А.Васильевой Москва «Мозаика-Синтез», 2014
• “Туган телдә сөйләшәбез” Ф.В.Хәзрәтова
“Математикага өйрәнәбез” З.Г.Шәрәфетдинова, И.Җ.Хәбибуллина, Ф.В.Хәзрәтова
“Сүрәтләү эшчәнле һәм конструкцияләү” Р.М. Зиннатова, Л.Ә.Гарәева, А.Г.Зворыкина

Төркемдә белем бирү процессын оештыру балалар бакчасы педагоглары иҗат иткән автор проектлары һәм методик кулланмаларда чагылыш тапты.

**1.5 *Төркемдә тәрбияләнүче балалар турында белешмә***

| № | Балаларның яше | Барлыгы | Малайлар | Кызлар | Норма буенча | Нормадан артыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 9 | 4-5 яшь | 14 | 8 | 6 | 14 | юк |

Барлык балалар да татар милләтеннән

***1.6 Төркемдә тәрбияләнүче балаларның гаиләләре турында белешмә***

**Таблица 2**

| ***Гаилә составы тулы*** | ***Гайлә составы тулы булмаган*** | ***Төркемнең милли составы:*** |
|---|---|---|
| 14 | юк | Татар гаиләсе -14 |

***9 нчы төркемнең паспорты***

| **тулы гаилә** | **күп балалы** | **аерылган** | **югары белемле** | | **урта белемле** |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | **эти** | **эни** | **эти** |
| *14* | *4* | *юк* | *10* | *12* | *4* |

***1.7 Балалар психик үсешенең яшь үзенчәлекләре.***

Мәктәпкәчә урта яшьтәге балаларның уен эшчәнлегендә үзара рольләр багланышлары барлыкка килә. Бу исә мәктәпкәчә яшьтәге балаларның үзләрен кабул ителгән рольдән аера башлауларын күрсәтә. Уен барышында рольләр алмашынырга мөмкин. Уен гамәлләре балаларның үзләре өчен түгел, уен мәгънәсе өчен башкарыла башлый. Балаларның уендагы һәм чын барлыктагы арадашлыгы бер-берсеннән аерыла.

Сурәтләү эшчәнлеге шактый зур үсеш кичерә. Рәсем предметлы һәм детальләштерелгән төс ала. Кешенең график сурәте гәүдә, күзләр, авыз, борын, чәчләр, кайбер чакта кием һәм аның детальләре булуы белән сыйфатлана. Сурәтләү эшчәнлегенең техник ягы камилләшә. Балалар төп геометрик фигураларны ясый, кәгазьдән кайчы белән кисеп ала, сурәтләрне кәгазьгә ябыштыра алалар һ.б.

Конструкцияләү эшчәнлеге катлаулана. Корылмалар 5–6 детальдән торырга мөмкин. Бала үзе уйлаганча конструкцияләү күнекмәләре, шулай ук гамәлләрнең эзлеклелеген планлаштыру формалаша. Баланың хәрәкәтләнү өлкәсе вак һәм эре моториканың позитив үзгәрешләре белән сыйфатлана. Җитезлек, хәрәкәтләр координациясе үсеш кичерә. Балалар бу яшьтә, үзләреннән кечерәкләргә караганда, тигезлекне яхшырак саклыйлар, кечерәк киртәләр аша атлап чыгалар. Туплы уеннар катлаулана. Мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең уртанчы төркеменнән күчү ахырына балаларның аңга кабул итүе югарырак баскычка күтәрелә. Балалар теге яки бу предмет охшаган форманы атау сәләтенә ия булалар. Катлаулы объектларда гади формаларны аерып ала һәм гади формалардан катлаулы объектларны торгыза алалар. Балалар предметлар төркемнәрен сиземләнүче билге (зурлык, төс) буенча тәртипкә салырга; биеклек, озынлык һәм киңлек кебек параметрларны аерырга сәләтле.

Тирәлектә ориентлашу камилләшә.

Хәтер күләме үсә. Балалар 7–8 предметның атамасын истә калдыралар. Ирекле хәтер сәләте үсә башлый: балалар истә калдыру биремен кабул итәргә сәләтле, өлкәннәр кушкан йомышларны хәтерлиләр, зур булмаган шигырьләр ятлый алалар һ.б. Образлы фикерләү үсә башлый. Балалар, катлаулы булмаган мәсьәләләрне чишү өчен, схемалаштырылган гади сурәтләр кулланырга сәләтле. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар схема буенча төзи, лабиринт мәсьәләләрне чишә алалар. Алдан күзаллау сәләте үсеш кичерә. Объектларның тирәлектә урна-

шулары буенча балалар аларның үзара тәэсир итешүе нәтиҗәсендә нәрсә булачагын әйтә алалар. Ләкин бу очракта аларга башка күзәтүче позициясенә басу һәм образны эчке планда үзгәртү кыен бирелә. Әлеге яшьтәге балалар өчен Ж. Пиаженың мәгълүм феноменнары (микъдар, күләм һәм зурлык саклану) хас. Мәсәлән, аларга кара төстәге өч кәгазь түгәрәк һәм ак төстәге җиде кәгазь түгәрәк тәкъдим итеп, «Нинди түгәрәкләр күбрәк — караларымы әллә акларымы?» дип сорасак, балаларның күпчелеге ак түгәрәкләрнең күбрәк булуын әйтер. Әгәр инде «Кайсы түгәрәкләр күбрәк — акларымы әллә кәгазьдән киселгәннәреме?» дигән сорау куйсак, җавап шундый ук булачак — аклары күбрәк.

Хыял алга таба үсеш кичерә. Аның оригинальлек һәм ireклелек кебек үзенчәлекләре формалаша. Балалар бирелгән темага мөстәкыйль рәвештә әкият уйлап чыгара алалар. Игътибарның тотрыклылыгы арта. Бала 15–20 минут дәвамында тупланып эшли ала. Ул, нindidер гамәлләр кылганда, хәтерендә катлаулы булмаган шартны саклап торырга сәләтле.

Мәктәпкәчә урта яшьтә авазларны әйтү һәм дикция яхшыра. Сөйләм балалар активлыгы предметына әверелә. Балалар уңышлы рәвештә хайваннар тавышларын охшатып кабатлыйлар, интонация белән теге яки бу персонажларның сөйләмнәрен күрсәтә алалар. Сөйләмнең структурасы, рифмалар аларда кызыксыну уята. Сөйләмнең грамматик ягы үсеш кичерә. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар грамматик кагыйдәләр нигезендә сүзләр иҗат итү белән шөгыльләнәләр. Балалар бер-берсе белән аралашканда, аларның сөйләменә ситуациягә бәйлелек хас, өлкән кеше белән аралашканда, баланың сөйләме ситуациягә бәйсез рәвеш ала. Бала һәм өлкән кеше аралашуының эчтәлеге үзгәрә. Ул баланың конкрет халәте чикләреннән чыга. Танып белү әйдәүче мотивка әверелә. Бала аралашу процессында алган мәгълүмат катлаулы һәм аңлау өчен кыен булырга мөмкин, әмма ул аңарда кызыксыну уята. Балаларда өлкән кеше ягыннан ихтирам ителү ихтыяҗы формалаша, алар өчен аның мактавы аеруча мөһим булып чыга. Бу исә балаларның кисәтүләргә карата артык үпкәләүчәнлегенә китерә. Артык үпкәләүчәнлек яшь феномены булып тора. Яшьтәшләре белән үзара мөнәсәбәтләргә сайланганлык хас, бу бер баланы икенчесенә караганда якынрак итүдә күренә. Уеннар уйнаганда даими партнерлар барлыкка килә. Төркемнәрдә лидерлар аерылып чыга башлый. Көндәшлек, ярышучанлык барлыкка килә. Соңгысы үзеңне башкалар белән чагыштыру өчен мөһим, ул «Мин» образының үсешенә, аны детальләштерүгә китерә. Яшьнең төп казанышлары уен эшчәнлеге үсеше белән, роль һәм чынбарлык арасында үзара бәйләнешләр барлыкка килү килү; сурәтләү эшчәнлеге үсеше; уйлаган буенча конструкцияләү, планлаштыру; аңга кабул итүне камилләштерү, образлы фикерләү һәм хыял үсеше, танып белү позициясенең эгоцентриклыгы; хәтер, игътибар, сөйләм, танып белү ихтыяҗы үсеше; өлкәннәр ягыннан ихтирамга ихтыяҗ формалашу, үпкәләүчәнлек, көндәшлек, яшьтәшләре белән ярышучанлык барлыкка килү; «Мин» образының алга таба үсеше, аны детальләштерү белән бәйләнгән.

### *1.7. Балаларның гомуми белем бирү программасын үзләштерүдә планлаштырылган нәтиҗәләр.*

Балаларның эшчәнлеген планлаштырганда һәр баланың үсеш дәрәҗәсе һәм аның белән индивидуаль эшләү исәпкә алына.

***Тәрбия бурычлары:***

Балаларның сәламәтлеген ныгыту, организмнарын чыныктыру эшен дәвам итү, төп хәрәкәтләрне дөрес итеп башкару күнекмәләре формалаштыру. Барлык төр эшчәнлектә гәүдәне дөрес тотарга гадәтләндерү. Хәрәкәт эшчәнлегендә мөстәкыйльлек һәм иҗадилык тәрбияләү. Культура-гигиена күнекмәләре булдыру.

Балаларның күзәтүчәнлек һәм кызыксынучанлыгын арттыру, аларны иҗтимагый тормыш, табигать предметлары, күренешләре белән таныштыруны дәвам иттерү. Предметларның һәм тере объектларның аерым өлешләрен һәм характерлы билгеләрен (төсе, формасы, зурлыгы) аерып күрсәтә белергә, аларны шул билгеләргә карап чагыштырырга, төркемнәргә аерырга өйрәтү. Предметлар һәм күренешләр турында гомуми кузаллау формалаштыру, алар арасында

иң гади бәйләнешләр урнаштырырга өйрәтү. Балаларның педагоглар белән конкрет ситуация чикләреннән чыккан мәгълуматларны уртаклашасы килү теләкләрен канәгатьләндерү. Аларның фикерләренә артык таләпчән булмау. Туган йортка, туган якка, балалар бакчасына мәхәббәт тәрбияләүне дәвам итү.

Балаларның сүзлек запасын баету, активлаштыру, авазларны дөрес әйтергә өйрәтү, сөйләм культурасын камилләштерү өстендә эшне дәвам итү. Бирелгән тема буенча әңгәмәдә актив катнашырга. Үз тәҗрибәләреннән чыгып. Уенчыклар турында, сюжетлы рәсемнәр буенча хикәяләр төзергә ярдәм итү. Якын кешеләрнең һөнәрләре белән таныштыру, хезмәтләренең мөһимлеге турында аңлату. Үзләренең хезмәт күнекмәләрен камилләштерү.

Эшне төгәл үтәргә, башлаган эшне ахырына җиткерергә, үз хезмәтенең башкалар өчен әһәмиятен аңлый белергә өйрәтү.

Балаларда тыйнаклык, өлкәннәргә һәм яшьтәшләренә карата ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү, гадел, көчле, кыю булырга теләк, омтылыш булдыру; ямьсез кыланышлары өчен ояла белү сыйфаты тәрбияләү. Еш мактау, өлкәннәрне нәрсә белән сөендерүләрен, гаҗәпкә калдыруларын аңлату. Уенчыкларга, китапларга, башка әйберләргә сак мөнәсәбәт тәрбияләү.

Балаларның әйләнә-тирәдәге матурлыкны күрә белүләрен, табигатьтә, көнкүрештә, уен вакытларында әхлакый-нәфасәти тойгыларын үстерү.

Сәнгать әсәрләренең эчтәлегенә төшенә, музыка, әкият, хикәяләрне игътибар белән тыңлый белүләренә ирешү. Сәнгатьнең төрле төрләренә кызыксыну тәрбияләү. Рәсем ясаганда,әвәләгәндә, төрле әсәрләрне сәхнәләштергәндә балаларның образга керә алу сәләтләренүстерү; шигырьләрне сәнгатьле итеп сөйләргә, җырларга, бию хәрәкәтләрен көйгә туры китереп башкарырга өйрәтү.

Бәйрәмнәр, күңел ачу чаралары вакытында балаларны мәдәни җәүһәрләр белән таныштыру, җәмгыятьтә аралаша белү күнекмәләре формалаштыру.

## *II. Эш программасының эчтәлек бүлеге*

### *2.1 Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге*

| | |
|---|---|
| ***1. “Физик үсеш”*** | “Физик культура” балаларда физик культура шөгыльләрендә кызыксыну һәм аңлы караш, гармонияле физик үсеш формалаштыру масксатларын тормышка ашыруга юнәлтә һәм белем бирү бурычларын билгели. |
| “Сәламәтлек” | Балаларның сәламәтлекләрен ныгыту, организмнарын чыныктыру, аның функцияләрен камилләштерү эшен дәвам итү. Балаларның хәрәкәт эшчәнлеген оештыруның төрле формаларында хәрәкәтләрне төгәл, дөрес итеп башкару күнекмәләре булдыру. Хәрәкәтләрнең матур, нәзакәтле, сәнгатьле булуларына ирешү. Хәрәкәт эшчәнлегендә мөстәкыйльлекне, иҗади мөмкинлекләрне үстерү. |
| “Балаларның психик һәм физик сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту” | Һава, кояш, судан файдаланып, чыныктыру чаралары комплексын уздыру. Көндәлек режим нигезендә балаларның һавада йөрүләрен тәэмин итү.<br>Көн саен 6-8 минутлык иртәнге гимнастика ясау.Төрле хәрәкәтле уеннар оештыру һәм үткәрү. Балаларны йөзәргә өйрәтү. Елына ике тапкыр 45 шәр минут спорт бәйрәме үткәрү.<br>Балаларны физкультура җиһазларыннан һәм хәрәкәтле уен атрибутларыннан мөстәкыйль һәм иҗади файдаланырга өйрәтү. |
| “Культура-гигиена | Балаларны пөхтәлеккә, тышкы кыяфәтләрен тәртиптә тотарга |

| | |
|---|---|
| күнекмәләрен тәрбияләү” | өйрәтүне дәвам итү. Мөстәкыйль рәвештә юыну гадәте тәрбияләү, ашар алдыннан, туалеттан соң кулларны сабынлап юарга гадәтләндерү. Тарактан, кулъяулыктан файдаланырга өйрәтү. Тәртипле ашау күнекмәләре булдыру: аз-аз гына кабып ашарга, яхшылап чәйнәргә, салфеткадан дөрес файдаланырга өйрәтү, ашаганнан соң авызны чайкарга гадәтләндерү. |
| “Сәламәт тормыш нигезләрен формалаштыру ” | Тойгы органнарын аера белү осталыкларнын үстерү (күз, авыз, борын, колак)<br>Файдалы һәм зарарлы азык-төлек турында күзаллау булдыру. Сәламәтлекнең әһәмиятен аңлату, сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү өчен шартлар тудыру.  Үз сәламәтлегенә һәм якын кешеләрнең сәламәтлегенә сакчыл караш тәрбияләү.<br>Көндәлек тормышта гигиена күнекмәләрен үтәүгә һәм пөхтәлек булдыруга ихтыяҗ формалаштыру. |
| “Физик культура” | “Физик культура” балаларда физик культура шөгыльләрендә кызыксыну һәм аңлы караш, гармонияле физик үсеш формалаштыру масксатларын тормышка ашыруны юнәлтә һәм белем бирү бурычларын билгели. |
| “Физик сыйфатларны үстерү” | Балаларның хәрәкәт осталыкларын, күнекмәләрен үстерү. Кул һәм аяк хәрәкәтләрен яраклаштырып йөрү һәм йөгерү күнекмәләрен ныгыту. Шуышырга, үрмәләп йөрергә; предметлар аркылы чыгарга өйрәтү. Ике аяк белән бер урында сикергәндә һәм алга таба сикереп барганда көч белән этелергә һәм җиргә дөрес төшә белергә өйрәтү.<br>Ыргытканда дөрес торыш алу, тупны уң һәм сул куллар белән җиргә бәреп сикертү, өскә чөю күнекмәләрен ныгыту.<br>Төрлечә тезелергә; бер-бер артлы йөргәндә дистанция сакларга өйрәтү. Психофизик сыйфатлар: тизлек. түземлек, җитезлекләрен үстерү. |
| ***2.“Социаль- коммунатив үсеш”*** | **“Социальләштерү”** белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның социаль характердагы беренчел күзаллауларын үзләштерү һәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү максатларын тормышка ашыруга юнәлтә һәм белем бирү бурычларын билгели. |
| “Уен эшчәнлегенең үсеше” | Уеннарның эчтәлеген баету. Төркемнәргә оешып , бергәләп мөстәкыйлҗ уеннар оештыра белүләрен куәтләү. Балаларда үзара уңай мөнәсәбәт формалаштыру, оешканлык. Уен кагыйдәләрен үти белүчәнлек, тотнаклылык тәрбияләү. |
| “Сюжетлы-рольле уеннар” | Уеннарның сюжетларын үстерү һәм баету эшен дәвам итү. Уеннарда берләшә, рольләрне бүлә, уен гамәлләрен башкара, уенның төп максатын истә тотып эш итә белүләрен камилләштерү.<br>Балаларны уен өчен шартлар тудырырга өйрәтү. Балаларның сюжетлы-рольле уеннар вакытында төзелеш материалларыннан-корылмалардан файдалану осталыкларын үстерү. Балалар арасында дусларча мөнәсәбәт булдыру, иптәшләренең фикерләре, теләге белән исәпләшергә, бер-береңә ярдәм итәргә өйрәтү.<br>Роль бүлешкәндә уен эчтәлеген катлауландыруда , атрибутлар файдалануда мөстәкыйльлекләрен арттыру. |
| “Хәрәкәтле уеннар” | Төрле уеннарда балаларның хәрәкәт активлыгын үстерүне дәвам итү.<br>Психофизик сыйфатлар тәрбияләү, әйләнә-тирәдә ориентлашырга өйрәтүне дәвам итү. Яштәшләре белән зур булмаган төркемнәргә бүленеп, мөстәкыйлҗрәвештә уеннар оештыра белүләренә булышлык итү.<br>Уен кагыйдәләрен тәрбиячекисәтүеннән башка да үтәргә өйрәтү.<br>Уен вакытларында иҗади мөмкинлекләрен(уен вариатларын уйлап |

| | |
|---|---|
| | табу, хәрәкәтләрне төрләндерү) үстерү. |
| “Театральләштерелгән уеннар” | Тагын да катлаулырак уен күнекмәләре булдыру нәтиҗәсендә, балаларның сәхнә уеннары белән кызыксынуларын арттыру.<br>Музыкаль, сүзле, күрсәтмә образлар кулланып, башкару күнекмәләрен үстерү. Образларны гәүдәләндерү өчен төрле нәфасәти чаралар кулланып, балаларны катлаулы булмаган тамаша уйнарга өйрәтү. Герой кичерешләрен сиземләргә һәм аңларга, рольләрдә башка персонажлар белән үзара бәйләнешкә керергә өйрәтү.<br>Балаларга уен өчен урын, уен материаллары биреп, режиссерлык сәләтләрен үстерү. Сәхнәләштерелгән уеннарда образлы уенчыклардан файдалана белү күнекмәләре бирү. |
| “Дидактик уеннар” | Балаларны предметларның үзлекләре турындагы күзаллауларын ныгытуга, аларны тышкы билгеләренә карап чагыштыра, төркемли белүгә юнәлтелгән дидактик уеннар уйнарга өйрәтү.<br>Балаларның сиземләү һәм тою, ишетү сәләтләрен камилләштерү (капшап карап, тәмен татып, яңгырашы буенча). Уеннар вакытында игътибарлылык, күзәтүчәнлек сыйфатлары тәрбияләү.<br>Балаларның гади өстәл уеннары кагыйдәләрен үзләштерү омтылышларын хуплау. |
| “Әхлак тәрбия нормалары белән таныштыру” | Әхлак нормалары: яхшы күңеллелек, намуслылык, гаделлек, кеше хәленә керә белүчәнлек турында күзаллау формалаштыру. Үзенең һәм яштәшләренең кылган эшләрен дөрес бәяли белергә өйрәтү.<br>Балалар арасында үзара уңай мөнәсәбәтләр формалаштыру эшен дәвам итү; *Мин* образын формалаштыру. Ярамаган гамәлләре өчен ояла белү, тыйнаклык сыйфатлары тәрбияләү.Үтенечен әдәпле генә аңлата, ярдәмнәре өчен өлкәннәргә, яшьтәшләренә рәхмәт әйтә белергә өйрәтүне дәвам итү.<br>Әйберләргә карата сак мөнәсәбәт тәрбияләү, алардан файдалана белергә, ватмаска, пычратмаска, аларны пөхтә итеп урынына җыеп куярга гадәтләндерү. |
| “Гаилә, гражданлык төшенчәләрен аңлату, патриотик хисләр тәрбияләү, дөнья берләшмәсенә катнаш булуларын исбатлау” | *МИН* образын формалаштыру. Үзеңне аңлый белергә ярдәм итү. Үзләренә кагылышлы төрле мәгълүмәт бирү (син-кыз, синең күзләрең кара, син уйнарга яратасың), үткән эш-гамәлләре һәм анда булган үзгәрешләр турында сөйләү.<br>**Гаилә.** Балага гаиләнең үзе белән яшәүче барлык кешеләрдән торуын аңлату. Балаларның өйдәге көндәлек вазыйфалары белән кызыксыну. Якын туганнарын белергә, атарга өйрәтү, аларга карата ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү. Балаларда туганлык мөнәсәбәтләре 9улы, әти, әни, кызы) турында күзаллаулар булдыру.<br>**Балалар бакчасы.** Балаларны балалар бакчасы, андагы хезмәткәрләр белән таныштыруны дәвам итү. Бина эчендә һәм уен мәйданчыгында, балалар бакчасы тирәсендә ориентлаша белү күнекмәләрен камилләштерү. Юл йөрү куркынычсызлыгы кагыйдәләрен белүне ныгыту.<br>**Туган ил.** Туган якка мәхәббәт тәрбияләүне дәвам итү; туган шәһәренең иң матур һәм истәлекле урыннары турында сөйләү.<br>**Безнең армия.** Балаларның Армия, Ватанны саклаучылар турында күзаллауларын киңәйтү. Туган илне, аның тынычлыгын саклауның никадәр авыр, ләкин мактаулы икәнен төшендерү. Балалар бакчасына сугыш ветераннарын кунакка чакыру, алар белән әңгәмә үткәрү. |
| “Иминлек” | “Иминлек” белем бирү өлкәсе эчтәлеге үз тормышының куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң (әйләнә-тирә дөнья |

| | |
|---|---|
| | куркынычсызлыгы) алшартларын формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтә һәм белем бирү бурычларын билгели. |
| “Тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен формалаштыру” | Балаларны балалар бакчасында үз-үзләрен тотуның иң гади кагыйдәләре белән таныштыру.<br>Тормышта була торган куркыныч чыганаклар турында күзаллаулар булдыру |
| “ Юлларда хәвер-хәтерсез йөрү тәртибе формалаштыру” | Юлларның машиналар һәм җәяүлеләр йөри торган өлеше белән таныштыру. Светофор белән танышу. Күрү сигналлары ярдәмендә йөрергә өйрәтү.<br>Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү.<br>Хәрәкәт итү чараларының атамалары һәм аларны файдалану максатлары белән таныштыру.<br>Транспорт төрләре турында беренчел күзаллауларын булдыру.<br>Тавыш чыганагының урынын билгели белү.<br>Өлкәннәр хезмәте турында күзаллау формалаштыру.<br>“Автобус”, “Трамвай” с/р уеннар булдыру өчен предметлы-уенлы мохит булдыру.<br>Җәмәгать транспортында аралашу культурасы белән бәйле репликаларны хуплау.<br>Су һәм ком белән уеннарны хуплау. |
| ***3.“Танып белү үсеше”*** | Балаларның танып белүен үстерүгә юнәлтелгән максатларын тормышка ашыру һәм интелектуаль үсү өчен түбәндәге мәсьәләләрне чишәргә кирәк.<br>Сенсорик тәрбия.<br>Иҗади эшчәнлекне  үстерү.<br>Гади математик күзаллауларны формалаштыру.<br>Бербөтен дөнья картинасын, балаларның дөньяга карашын киңәйтүне формалаштыру. |
| “Танып-белү, тикшерү һәм иҗади эшчәнлекне үстерү” | Тикшерү, кызыксынуны хуплап гади күзәтүләр үткәрү. Төрле ысуллар һәм тәҗрибәләр ярдәмендә предметны тикшерү (бата-батмый).<br>Катлаулы булмаган төзелешләрне анализлау. Конструктив осталыкларын тормышка ашыру.<br>Төп төзелеш кисәкләрен аера, таный, исемен атый белүне ныгыту(кубик, пластина, кирпеч, цилиндр). Яңа төзелешләр уйлап чыгару сәләтен үстерү. Төзелештә төп кисәкләрнең төрле төсен куллана белү. Әйбәт килеп чыккан төзелешкә шатлану хисе уяту.<br>Кирпеч, пластиналарны буйга куеп, бер-берсенә ныгытып беркетү, бертигез аралык калдыра  белүне формалаштыру.<br>Төзелешне ике төр ысул белән үзгәртә белүне формалаштыру: бер детальне башка белән алмаштырып яисә аны буйга, озынлыкка куеп (биек, тәбәнәк бина; кыска, озын поезд).Үзлектән уйлап чыгарып төзү осталыгын үстерү.<br>Балаларны  уйнаганнан соң төзелеш кисәкләрен чиста-пөхтә итеп җыештырып куярга күнектерү. |
| “Иң гади математик күзаллауларын формалаштыру” | **Сан һәм санау**<br>Балаларга күплек сандагы әйберләрне билгеләре төрле булган аерым предметлардан төзергә мөмкин булуын төшендерү; тигез һәм тигез булмаган төркемнәрне чагыштырырга өйрәтү. 5 кә кадәр санарга өйрәтү. Зуррак төркемнән беркадәр предметларны аерып алырга өйрәтү. Предметларны капшап карап, ишетеп санарга өйрәтү хәрәкәтләрне саный белү күнекмәләре бирү.<br>**Зурлык.** |

| | |
|---|---|
| | Ике предметны зурлыгына карап чагыштыра белүләрен камилләштерү, чагыштыру нәтиҗәләрен сөйләмдә чагылдыру (озынрак-кыскарак, киңрәк-таррак, юанрак-нечкәрәк).<br>Зурлыкны күрсәтүче ике билге буенча (кызыл тасма яшел тасмадан озынрак һәм киңрәк) предметларны чагыштырырга өйрәтү.<br>Төрле озынлыктагы , киңлектәге предметны арта һәм кими бару тәртибендә урнаштырып чагыштырырга, предметның урнашу тәртибен күрсәтергә өйрәтү.<br>**Форма.**<br>Геометрик фигуралар турында күзаллауларын киңәйтү.балаларны турыпочмаклык белән таныштыру, аны түгәрәк. Квадрат, өчпочмак белән чагыштыру. Туры почмаклыкны танырга һәм әйтергә өйрәтү.<br>Фигураларның төрле үлчәмдә була алуын аңлату.<br>Предметларның формаларын геометрик фигуралар белән чагыштырып әйтә белү күнекмәләре бирү: яулык-квадрат, тәлинкә-түгәрәк, туп-шар һ.б.<br>**Тирә-юньдә ориентлашу**<br>Балаларны юнәлешләр билгеләргә, әйтелгән юнәлештә (алга-артка, уңга-сулга) хәрәкәт итәргә; баланың үзенә карата предметларның торышын сүзләр белән (минем алдымда) аңлатып бирергә өйрәтү.<br>**Вакытта ориентлашу** Тәүлекнең бүленеше (иртә, көндез, кич, төн), тәүлек вакытларының эзлеклелеге турында баланың күзаллауларын киңәйтү. ***Кичә, бүген, иртәгә*** дигән төшенчәләр белән таныштыру. Бу сүзләрнең мәгънәләрен аңлату. |
| “Иҗади эшчәнлек” | Иҗади эшчәнлекне үстерү, аның нәтиҗәсе турында фикер алышу.Эшчәнлек нәтиҗәсен күзаллау, максатчан активлык күрсәтү. |
| “Дөнья картинасын үзләштерү, белем дәрәҗәсен үстерү” | Балаларны төрле эшчәнлек, зур булмаган предметлар дөньясы белән таныштыруны дәвам итү. Көнкүреш предметларның сыйфаты, үзенчәлекләре белән таныштыруны дәвам итү. Аларның төсен, формасын, зурлыгын билгеләргә өйрәтү. Әйберләрнең нинди материалдан (кәгазь, балчык, тукыма, резина) ясалуы турында сөйләү. Материал һәм аның вазыйфасы, корылма һәм аның вазыйфасы арасындагы бәйләнешне күрә белергә өйрәтү. Балаларның әйбернең ничек һәм кайда эшләнгәнлеген беләсе килү теләген хуплау. Балаларның җәмәгать транспорты (автомашина, автобус, поезд) турындагы белемнәрен арттыру. |
| “Табигать белән таныштыру” | Балаларның күптөрле табигать күренешләре турындагы күзаллауларын киңәйтү. Табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турындагы белемнәрен ныгыту. Экологик система турында башлангыч төшенчә бирү: табигатьтәге һәр үсемлек һәм җәнлекнең яшәү тирәлегенә яраклашуын, җайлашуын аңлату.<br>Яшелчә, җиләк-җимешне танып, исемнәрен әйтә белергә өйрәтү.<br>Үсемлекләрнең тереклек итәләре икәнлекләрен аңлату (аларның үсүе өчен билгеле бер шартлар – җир, су, җылылык, яктылык кирәк)<br>Йорт хайваннары һәм аларның балалары турында белемнәрен киңәйтү. Кешеләрнең йорт хайваннарын карау-тәрбияләүгә бәйле хезмәтләре белән таныштыру.<br>Бөҗәкләр турындагы күзаллауларын ныгыту.<br>Табигый шартларда яшәүче кыргый хайваннарның тормышы, нәрсә белән туклануы, кышкы шартларда тереклек итүгә ничек җайлашулары турында күзаллауларын киңәйтү.<br>Хайваннарның яшәү урыны белән үзара бәйләнешне күрсәтү.<br>Балаларда табигатьне ярату хисләре, аңа сак караш тәрбияләү. |

| | |
|---|---|
| “Хезмәт” | Балаларда хезмәткә карата уңай мөнәсәбәт, хезмәт итү теләге тәрбияләү. |
| “Өлкәннәр хезмәте” | Балаларда өлкәннәрнең хезмәт эшчәнлеген көчләреннән килгәнчә ярдәм итәсе килү теләге тудыру.<br>Балаларның өлкәннәр хезмәте, аларның һөнәрләре турында белемнәрен киңәйтү. Аларны төзүчеләр, авыл эшчәннәре, транспорт, элемтә, тегү сәнгате хезмәткәрләренең хезмәте белән таныштыру. Хезмәт кешесенә хөрмәт тәрбияләү. |
| “Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү” | Мөстәкыйль киенә, чишенә белү күнекмәләрен камилләштерү; киемнәрен пөхтәләп элеп куярга өйрәтү. Өстәл артында үзләрен әдәпле тотарга гадәтләндерү.<br>Рәсем, әвәләү, кисеп ябыштыру эшчәнлеге алдыннан мөстәкыйль рәвештә үзенең эш урынын әзерләргә, аны җыеп куярга өйрәтү. |
| “Хуҗалык-көнкүреш хезмәте” | Балаларны төркем бүлмәсен һәм мәйданчыкны тәртиптә тотуда мөстәкыйльлеккә: төзелеш материалларын, уенчыкларны урынына җыеп куярга, аларны юарга, язын һәм көзен, тәрбияче белән берлектә, мәйданчыктагы чүп-чарны җыярга, веранданы себерергә, кышын кар көрәргә өйрәтү. |
| “Табигатьтәге хезмәт “ | Мөстәкыйль рәвештә үсемлекләргә су сибү. Су савытларын юу. Җимлеккә азык салу күнекмәләрен формалаштыру.<br>Кышлаучы кошларны бергәләп ашату.<br>Яшелчә бакчасында һәм чәчәклектә эшләргә өйрәтү. Эш коралларын тәртипкә китерергә гадәтләндерү. |
| “Хезмәт хәзинәләрен саклый белергә өйрәтү” | Өлкәннәр хезмәтенә уңай караш тәрбияләү. Балаларда өлкәннәрнең хезмәт эшчәнлеген көчләреннән килгәнчә ярдәм итәсе килү теләге тудыру. Таныш һөнәр кешеләренә хөрмәт тәрбияләү эшен дәвам итү.<br>Өлкәннәренең хезмәте турында беренчел күзаллау булдыру.<br>һәр уңай очракта балаларга таныш һөнәрләр турында сөйләү, аларның хезмәт төрләре һәм хезмәт нәтиҗәләре турындагы күзаллауларын киңәйтү. Таныш һөнәр кешеләренә хөрмәт тәрбияләү эшен дәвам итү. |
| ***4. “Сөйләм үстерү”*** | **“Сөйләм үстерү” белем бирү** өлкәсе туган телнең нечкәлекләрен, тирәнлеген өйрәнү, сүзнең мәгънәсенә төшенү, логик фикерләү сәләтен үстерү, матур әдәбият әсәрләре белән кызыксыну, аваз культурасы, бәйләнешле һәм кара-каршы сөйләшә белү (диалогик сөйләм) күнекмәләрен камилләштерү, сәнгатьле сөйләмне үстерү бурычларын гамәлгә ашыра. Бу өлкәдәге эшчәнлек әңгәмә, үстерелешле диалог(балалар сорау бирә, сорауларга җавап кайтара), сәхнәләштерү, өстәл театры карау, рәсемнәр карау, алар буенча хикәя төзү, уен-викториналар; тасвирлау, үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү, хикәяне дәвам итеп сөйләү кебек эш формаларын күздә тота. |
| “Сөйләм үстерү мохите” | Балаларның үзләрен әйләндереп алган гадәти тирәлектән читтә булган предметлар, күренешләр турында беләсе килү ихтияжларын канәгатьләндерү, кызыксынучанлыкларын үстерү.<br>Балаларны тыңлап, җавапларына төгәллек кертү, предмет, күренеш, эш-гамәлләрнең үзенчәлекләрен төгәлрәк чагылдыручы сүзләр табарга ярдәм итү; фикерләрен аңлаешлы һәм эзлекле итеп әйтергә булышу.<br>Яшьтәшләре белән ягымлы булырга, әдәпле аралашырга өйрәтүне дәвам итү. |

| | |
|---|---|
| | Үзләренең уй-фикерләрен яшьтәшләренә, өлкәннәргә аңлаешлы итеп сөйли белергә; ярдәмнәре өчен аларга рәхмәт әйтә, үтенечен әдәпле генә аңлата белергә, кирәк булса гафу үтенергә өйрәтү. |
| “Сүз байлыгын үстерү” | Әйләнә-тирә дөнья турындагы белемнәрне тирәнәйтү, предметлар, вакыйгалар турындагы күзаллауларын киңәйтү, балаларның сүзлек запасын арттыру һәм активлаштыру.<br>Предметларны исемнәрен, аларның өлешләрен белдерүче сүзләрне сөйләмдә куллануны активлаштыру.<br>Еш кулланыла торган сыйфатларны, фигыльләрне, бәйлекләрне сөйләмдә кулланырга өйрәтү.<br>Сүзлекләренә һөнәрләрне белдерүче исемнәрне, эш-гамәлләрне чагылдыручы фигыльләрне кертү (табиб дәвалый, кан басымын үлчи, дару язып бирә) Әйберләрнең кайда, ничек урнашуларын, тәүлекнең кайсы вакыты булуын, кешеләрнең кәефен билгели белергә өйрәтү эшен дәвам итү.<br>Еш кулланыла торган күрсәтү алмашлыкларын (бу, анда һ.б.) төгәлрәк мәгънәле сүзләр белән белдерергә өйрәтү; антонимнар куллану (чиста-пычрак). Сөйләмдә гомумиләштерүче сүзләрне кулланырга өйрәтү (йорт җиһазлары, йорт хайваннары) |
| “Авазларны дөрес әйтә белү” | Тартык һәм сузык авазларның дөрес әйтелешен ныгыту; сызгырулы, чыжылдаучы, сонор (р,л) авазларын дөрес һәм ачык итеп әйтергә өйрәтү. Балаларның артикуляцион аппаратын үстерү.<br>Дикция өстендә эшләүне дәвам итү: сүзләрне ачык, дөрес итеп әйтә белүләрен камилләштерү.<br>Фонематик ишетү сәләтләрен үстерү: билгеле бер аваз белән башланган сүзләрне ишетеп аера белү, сүзләр әйтү.<br>Сәнгатьле сөйләм күнекмәләре булдыру. |
| “Сөйләмнең грамматик төзелеше” | Җөмләдә сүзләрне бәйләргә өйрәтүне дәвам итү. Сөйләмдә бәйлекләрне дөрес куллану күнекмәләрен камилләштерү.<br>Кайбер фигыльләрдән боерык фигыль ясау (киенә-киен) күнекмәләре булдыру. Исемнәрне күплек санда куллана белүләрен камилләштерү.<br>Сөйләмдә тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрнең иң гади төрләрен кулланырга өйрәтү. |
| “Бәйләнешле сөйләм” | Балаларның диалогик сөйләмен камилләштерүне дәвам итү. Актив рәвештә әңгәмәләрдә катнашырга; сораулар бирергә, сорауларга аңлаешлы итеп җавап кайтарырга өйрәтү.<br>Өлкәннәр кебек сөйләшү теләге тудыру, бирелгән сорауга дөрес җавап бирү-бирелмәвен ачыклау омтылышын хуплау.<br>Предмет, картиналарны тасвирлап сөйләп бирергә өйрәтү. Таратма карточкалар кулланып, бала үзе төзегән картина буенча хикәя төзү күнекмәләре бирү. Кечкенә әкиятләрне, балаларга ошаган өзекләрне сәхнәләштереп сөйли белү күнекмәләре бирү. |
| ***5.“Сәнгати – эстетик үсеш”*** | Халык җәүһәрләренә һәм профессиональ сәнгать әсәрләренә, әдәбиятка, музыкаль әсәрләрне тыңлау һәм башкаруга кызыксыну тәрбияләү. Сәнгатьнең төрле төрләрендәге сәнгати чаралар (төс, аваз, форма, хәрәкәт, ишарәләр) белән таныштыру, төрле сәнгать төрләрен сәнгать образы аша аерырга өйрәтү. |
| “Сәнгать белән танышу” | Балаларның сәнгатьне кабул итә белүләренә ирешү. Артист, рәссам, композитор һөнәрләре белән таныштыру. Курчак театры, күргәзмәләрне карау белән кызыксынучанлыкларын үстерү.<br>Сәнгать жанрларын һәм төрләрен аеру күнекмәләре формалаштыру: шигырь, табышмаклар, җырлар, музыка, рәсем, цирк, театр. |

| | |
|---|---|
| | Балалар яшәгән биналарның архитектура корылмалары икәнен аңлату. Төрле биналарның охшаш һәм аермалы билгеләрен табарга өйрәтү, мөстәкыйль рәвештә бинаның үзенчәлекләрен, өлешләрен күрсәтүләрен хуплау.<br>Балаларның рәсемнәрдә, аппликацияләрдә чын һәм әкияти корылмалар сурәтләүләрен хуплау.<br>Язучылар һәм шагыйрьләр иҗат иткән китаплар саклау үзәге булган китапханә белән таныштыру.Халык сәнгате әсәрләре белән таныштыру (такмаклар, әкиятләр, табышмаклар, җырлар)<br>Сәнгать әсәрләренә сак мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| “Нәфасәти үсеш мохите” | Балаларны төркем бүлмәсе, йокы бүлмәсе, аларның бизәлеше, уенчыклар белән таныштыру.<br>Тирә-якның матурлыгын күрә белергә өйрәтү, балаларга бигрәк тә охшаган предметны һәм күренешләрне атарга тәкъдим итү. |
| “Сурәтләү эшчәнлеге” | Балаларда сынлы сәнгатькә карата кызыксыну уяту. Рәсем ясарга, әвәләргә, кисеп ябыштырырга дигән тәкъдимнәрне балаларның хуплап кабул итүләренә ирешү. Нәфасәти кабул итү, иҗади уйлау, нәфасәти хисләр, предметларны карау, куллар ярдәмендә тикшереп өйрәнү күнекмәләре үстерүне дәвам итү, образлы күзаллаулар формалаштыру.<br>Мөстәкыйльлек, активлык, иҗади сәләт үстерү. Балалар иҗатын үстерү нигезе буларак, сәнгать турында күзаллауларын баету.<br>Бергәләп рәсемнәр ясау, әвәләү, аппликацияләр эшләү күнекмәләрен формалаштыруны дәвам итү. Иптәшләре эшләренә бәя бирергә өйрәтү. Сәнгатьлелек чараларын аерып күрсәтергә өйрәтү. |
| “Рәсем” | Балаларны сюжетлы композиция тудырырга өйрәтү.<br>Предметларның формасы, зурлыгы, өлешләрнең урнашу тәртибе турында күзаллау формалаштыру һәм ныгыту.<br>Сюжетны ясаганда, эчтәлегенә туры китереп, сурәтләрне кәгазь битендә дөрес урнаштырырга ярдәм итү. Балалар игътибарын предметларны зурлыклары буенча чагыштыра белүгә юнәлтү (агач биек, ә куак тәбәнәгрәк).<br>Таныш төсләргә һәм төсмерләргә яңаларын өстәү, бу төсләрне ничек китереп чыгару мөмкинлеге турында күзаллауларын формалаштыру.<br>Карандашны, пумаланы, фломастерны эш вакытында куллану күнекмәләрен ныгыту.<br>Катлаулы предметларны сурәтләгәндә аларның өлешләрен дөрес урнаштыра һәм чагыштырмача зурлыкларын дөрес күрсәтә белү күнекмәләрен формалаштыру. Дымково, Филимоново бизәкләре кулланып, декоратив композицияләр төзи белергә өйрәтү эшен дәвам итү. Городецк эшләнмәләре белән таныштыру. Городецк бизәкләре элементларын аера белергә; бизәлештә кулланылган төсләрне танып әйтә белергә өйрәтү. Рәсем ясаганда гәүдәне төз тотып утыру күнекмәләрен ныгыту. Пөхтәлеккә күнектерү: эш урынында чисталык, эшне тәмамлаганнан соң, эш материалларын урынына алып кую. |
| “Әвәләү” | Балаларның әвәләү белән кызыксынуларын үстерү. Балчыктан әвәләү күнекмәләрен ныгыту. Пластилинны түгәрәкләп һәм турыга тәгәрәтеп әвәләү, кысу, бөжра рәвешендә тоташтыру осталыкларын камилләштерү. Берничә кисәктән торган предметлар әвәләргә, пропорцияләрен саклап, кисәкләрен дөрес урнаштырырга өйрәтү.<br>Балчыктан әвәләгән төп формадан аерым кисәкләрне сузарга, форманың өстен шомартырга, кысу һәм сылау ысулы белән |

| | |
|---|---|
| | кисәкләрне тоташтырырга өйрәтү. Эш барышында таякчыклардан файдаланырга күнектерү. Әвәләгән әйберләргә таякчыклар ярдәмендә бизәкләр ясау теләкләрен хуплау. Эш барышында пөхтәлек тәрбияләү. |
| “Кисеп ябыштыру” | Балаларның кисеп-ябыштыру белән кызыксынуларын үстерү; сурәтләрне төрләндерү мөмкинлекләрен арттыру.<br>Кайчыны дөрес тотарга, аның белән дөрес эш итәргә күнектерү. Турыга кыска, озын тасмалар кисү күнекмәләре бирү. Тасмалардан төрле предметлар ясарга өйрәтү. Квадраттан түгәрәк, турыпочмаклыктан овал кисеп күрсәтү. Әлеге алым белән яшелчәләр, җиләк-җимешләр кисеп ябыштыру. Әзер формаларны 2 яки 4 кисәккә бүлеп эшне катлауландыру. Җайлап кына кисеп, пөхтә итеп ябыштырырга күнектерү. Активлык һәм иҗатка омтылышларын хуплау. |
| “Конструкцияләү” | Балаларның төзелеш детальләрен (куб, пластина, борыс) тану һәм атый белү осталыкларын үстерүне дәвам итү. Күргән корылмаларны искә төшереп, охшашлыклары буенча материаллар сайлап төзү күнекмәләре бирү. Тәрбияче күрсәткән конструкцияләү принцибын саклап корылманы биеклеккә, озынлыкка һәм киңлеккә мөстәкыйль үзгәртергә өйрәтү. Вак һәм эре төзелеш материалларыннан төрле корылмалар төзү;<br>Кәгазьдән конструкцияләргә: кырыйларын, почмакларын тәңгәл китереп, турыпочмаклы кәгазьне уртадан бөкләргә, төп формага детальләрен ябыштырырга өйрәтү.<br>Балаларны табыгый материаллардан: агач кайрысы, ботаклар, яфраклар, күркәләр, саламнан төрле әйберләр ясауга тарту. |
| “Музыка тәрбиясе” | Балаларда музыканы ярату хисләре, аны тыңлау теләге тәрбияләүне дәвам итү; музыка әсәрләрен тыңлаганда, эмоциональ халәт тудыру; уңай тәэсирләр алу; иҗади сәләтләрен үстерү. Музыка өлкәсендә белемнәрен үстерүгә булышлык итү. |
| “Матур әдәбият белән таныштыру” | Балаларны игътибар белән әкиятләр, хикәяләр, шигырьләр тыңларга өйрәтүне дәвам итү. Төрле алымнар һәм педагогик ситуацияләр кулланып, әсәрнең эчтәлеген дөрес аңлау, геройларның хәленә керә белү күнекмәләре булдыру. Баланың соравы буенча әкият, хикәя, шигырьләрнең аңа ошаган өзекләрен укып күрсәтү, әсәргә карата баланың шәхси мөнәсәбәтен булдыру. Әдәби әсәрләр белән кызыксынуын хуплау. Китаплар белән кызыксыну уяту юнәлешендә эшләүне дәвам итү. Балаларга таныш әсәрләрнең матур иллюстрацияләрнең мөһимлеген төшендерү (эчтәлек яхшырак аңлашыла; рәсемнәрне игътибар белән карасаң, күпме яңалык алып була). |

**2.2** ***4-5 яшьлек балалар белән эшне комплекслы-тематик планлаштыру.***

| Тема | Эшнең киңәйтелгән эчтәлеге | Йомгаклау чараларының үрнәк вариантлары |
|---|---|---|
| **Белем көне.** (августның 4 нче атнасы — сентябрьнең 1 нче атнасы) | Балаларда танып белү омтылышын, мәктәпкә, китапка кызыксыну үстерү. Балалар арасында дустанә, ягымлы мөгамәлә формалаштыру. Баланы балалар бакчасы белән якын социаль | Балалар бакчасы хезмәткәр ләренең ата-аналар белән берлектә оештырылган «Белем көне» бәйрәме. Балалар бәй рәмне әзерләмиләр, әмма |

| | | |
|---|---|---|
| | тирәлек буларак<br>таныштыруны дәвам итү (булып узган үзгәрешләргә игътибар юнәлтү: койма буялган, яңа өстәлләр алынган һ.б.), бакча хезмәткәрләренең һөнәрләре турында күзаллауларны киңәйтү (тәрбияче, тәрбияче ярдәмчесе, музыка җитәкчесе, табиб, ишегалды себерүче, аш пешерүче һ.б.). | конкурсларда, викториналарда актив катнашалар, үзләренең сәләтләрен күрсәтәләр. |
| **Көз.**<br>(сентябрьнең<br>2–4 нче атналары) | Балаларның көз турында күзаллауларын киңәйтү. Терек һәм терек булмаган табигать күренешләре арасында иң гади бәйләнешләр булдыру сәләтен үстерү (суытты — күбәләкләр юкка чыкты, чәчәкләр коелды һ.б.), сезонлы күзәтүләр алып бару. Авыл хуҗалыгы һөнәрләре, урманчы һөнәре турында күзаллауларны киңәйтү. Яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр турында (җирле, экзотик) белемнәрне киңәйтү. | «Көз» бәйрәме. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| **Халык мәдәнияте һәм традицияләре белән танышу.**<br>(мартның 2–4 нче атналары) | Халык уенчыклары турында күзаллауларны киңәйтү (Дымково уенчыгы, матрешка һ.б.). Халык кәсепләре белән таныштыру. Халык авыз иҗаты белән таныштыруны дәвам итү. Фольклорны балалар эшчәнлегенең барлык төрләрендә файдалану. Табигатьтә үз-үзеңне тоту куркынычсызлыгы кагыйдәләре турында күзаллауларны киңәйтү. Табигатькә сак караш тәрбияләү. Элементар экологик күзаллаулар формалаштыру. | Фольклор бәйрәме.<br>Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| **Мин дөньяның бер кешесе.**<br>(октябрьнең<br>1–3 нче атналары) | Сәламәтлек һәм сәламәт яшәү рәвеше турында күзаллауларны киңәйтү. Балаларның үз гаиләсе турында күзаллауларын киңәйтү. Гаиләдә туганлык мөнәсәбәтләре турында (ул, кыз, әти, әни һ.б) беренче күзаллаулар формалаштыру. Үзенең исемен, фамилиясен, яшен; әти-әнисенең исемен белүен ныгыту. Баланың әти-әнисенең һәнәрләре белән таныштыру. Якын өлкәннәр хезмәтенә карата хөрмәт тәрбияләү. | Сәламәтлек көне. |
| **Минем шәһәр, минем ил.**<br>(октябрьнең 4 нче атнасы ноябрьнең<br>2 нче атнасы) | Туган шәһәр (авыл) белән таныштыру.Туган як, аның тарихы һәм мәдәнияте турында башлангыч күзаллаулар формалаштыру. Туган якка мәхәббәт тәрбияләү. Транспорт төрләре һәм аларның үзенчәлекләре турында күзаллауларны киңәйтү. Шәһәрдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, элементар юл хәрәкәте кагыйдәләре турында күзаллауларны киңәйтү. Һөнәрләр | Спорт бәйрәме. |

| | | |
|---|---|---|
| | хакында күзаллауларны киңәйтү.<br>Россияне данга күмгән кайбер күренекле кешеләр белән таныштыру. | |
| **Яңа ел бәйрәме.**<br>(ноябрьнең 3 нче атнасы<br>декабрьнең 4 нче атнасы) | Яңа ел һәм Яңа ел бәйрәме тирәсендә балалар эшчәнлегенең барлык төрләрен (уен, коммуникатив, хезмәт, танып белү-тикшеренү, продуктив, музы-каль-сәнгати, укулар) оештыру. | «Яңа ел» бәйрәме. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| **Кыш**<br>(гыйнварның<br>1–4 нче атналары) | Балаларның кыш турында күзаллауларын киңәйтү. Терек һәм терек булмаган табигать күренешләре арасында иң гади<br>бәйләнешләр булдыру күнекмәләрен үстерү. Сезонлы күзәтүләр алып бару сәләтен, кышкы табигатьнең матурлыгын күрә белү, аны рәсемнәрдә, әвәләп ясауда чагылдыру күнекмәләрен үстерү. Кышкы спорт төрләре белән таныштыру. Кышын кешеләрнең үз-үзләрен куркынычсыз тоту кагыйдәләре турында күзаллау формалаштыру. Су һәм боз белән экспериментлар ясау барышында тикшеренү һәм танып белү кызык-сынуы формалаштыру. | «Кыш» бәйрәме.<br>Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| **Ватанны саклаучылар көне.**<br>(февральнең<br>1–3 нче атналары) | Балаларны «хәрби» һөнәрләр (солдат, танкист, очучы, диңгезче, чик сакчысы);хәрби техника (танк, самолет, хәрби крейсер); Россия флагы белән таныштыру. Ватанга мәхәббәт тәрбияләү**.** | Ватанны саклаучылар көненә багышланган бәйрәм.<br>Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| **8 Март**<br>(февральнең<br>4 нче атнасы —<br>мартның 1 нче атнасы) | Гаилә һәм әниләргә, әбиләргә мәхәб-бәт темасы тирәсендә балалар эшчәнлегенең барлык төрләрен (уен, коммуникатив, хезмәт, танып белү-тикшеренү, продуктив, музыкаль-сәнгати, укулар) оештыру. Тәрбиячеләргә, балалар бакчасының башка хезмәткәрләренә карата хөрмәт тәрбияләү. | 8 Март бәйрәме.<br>Балалар иҗаты<br>күргәзмәсе. |
| **Халык мәдә нияте һәм традицияләре белән танышу.**<br>(мартның 2–4 нче атналары) | Халык уенчыклары турында күзаллауларны киңәйтү (Дымково уенчыгы, матрешка һ.б.). Халык кәсепләре белән таныштыру. Балаларны Дымково һәм Филимоново бизәген өйрәнүгә җәлеп итү. Халык авыз иҗаты белән таныштыруны дәвам итү. Фольклорны балалар эшчәнлегенең барлык төрләрен оештырганда файдалану. | Фольклор бәйрәме.<br>Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| **Яз**<br>(апрельнең<br>1–4 нче атналары | Балаларның яз турында күзаллауларын киңәйтү. Терек һәм терек булмаган табигать күренешләре арасында иң гади бәйләнешләр булдыру күнекмәләрен үстерү, сезонлы күзәтүләр алып бару. Табигатьтә үз-үзеңне куркынычсыз тоту кагыйдәләре турында күзаллауларын | «Яз» бәйрәме. Балалар иҗаты<br>күргәзмәсе. |

| | | |
|---|---|---|
| | киңәйтү. Табигатькә сак караш тәрбияләү. Элементар экология күзаллауларын формалаштыру. | |
| **Җиңү көне** (апрельнең 4 нче атнасы майның 1 нче атнасы) | Патриотик тәрбияне гамәлгә ашыру.Туган илгә мәхәббәт тәрбияләү. Җиңү көненә багышланган бәйрәм турында күзаллаулар формалаштыру. Сугыш ветераннарына карата хөрмәт тәрбияләү. | Җиңү көненә багышланган бәйрәм. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| **Җәй** (майның 1–4 нче атналары) | Балаларның җәй турында күзаллауларын киңәйтү. Терек һәм терек булмаган табигать күренешләре арасында иң гади бәйләнешләр булдыру күнекмәләрен үстерү, сезонлы күзәтүләр алып бару. Җәйге спорт төрләре белән таныштыру. | «Җәй» бәйрәме.<br>Спорт бәйрәме. Балалар иҗаты<br>күргәзмәсе. |

### *2.3 Ата-аналар белән эшләүнең төп бурычлары.*

-Ата-аналарны балаларның психик үсешенең яшь үзенчәлекләре белән таныштыру.
– Балаларның хәрәкәт активлыгын үстерү һәм күтәренке кәеф булдыру өчен шартлар тудыру.
– Балаларны яшьтәшләре арасында үзләрен дөрес тотарга өйрәтү.
– Балаларның уй- фикерләрен камилләштерү, күрү, ишетү, тою-сиземләү сәләтен актив кулలануларына ирешү.
– Аралашу чарасы буларак, балаларның сүз байлыгын арттыру, сөйләм телләрен үстерү.

| *Ай* | *Ата-аналар белән эш темалары* |
|---|---|
| Сентябрь | 1.Ата-аналар җыелышы: “Уртанчылар төркеме. 2020 -2021 нче уку елына тәрбия һәм белем бирү бурычлары”<br>2. Балалар- бакчасында – әти-әниләр өчен стенд өчен киңәшләр.<br>3. Ата-аналарга балаларның портфолиосын ясарга тәкъдим итү<br>4. Ата-аналар өчен консультация “Балалар бакчасы һәм гаилә бердәм булса...”<br>5. Күргәзмә “Көзге могҗизалар”. Сөмбелә бәйрәме. |
| Октябрь | 1.Консультация: “Уен-тәрбиянең бер чарасы”.<br>2.Грипп һәм ОРВИ профилактикасы турында шәхси әңгәмәләр.<br>3.Ата-аналар өчен консультация “Сәламәт тәндә-сәламәт акыл”<br>4.Түгәрәк өстәл “Яхшылык белән тәрбиялибез” |
| Ноябрь | 1. Консультация: “Яратырга өйрәник”.<br>2. Әңгәмә: “Әдәпле булу-бәхетле булу”.<br>3. Әниләр көненә балаларның рәсем күргәзмәсе.<br>4. “Әнием - кадерлем. бәйрәм<br>5. “Салкын көннәрдә балаларны ничек киендерергә?” киңәшләр. |
| Декабрь | 1. “Туган ягымда кыш” Ата-аналар белән мәйданчыкны бизәү.<br>2. Яңа ел бәйрәменә әзерләнү. Төркем бүлмәсен бизәү. |

| | |
|---|---|
| | 3. “Оста куллар” яңа ел уенчыкларына конкурс.<br>4. “Ничек итеп балаларны пөхтәлеккә өйрәтергә” киңәшләр.<br>4. “Яңа ел бәйрәме”.<br>5. Ата-аналар җыелышы. |
| Гыйнвар | 1. Консультация “Эш яратып үссеннәр”.<br>2. “Балаларны чыныктыру чаралары” киңәшләр.<br>3. “Балага ничек җавап бирергә?” ата-аналар өчен консультация<br>4. Фото күргәзмә “Кышкы уеннар” |
| Февраль | 1. “Минем әтием” темасына рәсемнәр күргәзмәсе.<br>2. “Алтын куллы әтием” (кул эшләре күргәзмәсе)<br>3. «Культура-гигиена күнекмәләре тәрбияләү» консультация уздыру.<br>4. Түгәрәк өстәл “Балаларның уен эшчәнлеге” |
| Март | 1. “Әниләрнең уңган куллары” (кул эшләре күргәзмәсе)<br>2. “Минем әнием иң, иң, иң...” фотокүргәзмә.<br>3. 8 март бәйрәменә әзерләнү. Бәйрәмдә катнашу.<br>4. Ата-аналар өчен консультация “Әхлак тәрбиясе”<br>5. Нәүрүз бәйрәме |
| Апрель | 1.Әңгәмә.”Гаиләдә балаларның бер-берсе белән аралашуы.”<br>2. Анкеталар тутыру.Тема:“Мин нинди ата-ана”<br>3.Экскурсия “Бу минем бакчам”<br>4. Кош оялары ясау.<br>5. Ата-аналар җыелышы. |
| Май | 1. Җиңү көненә багышланган күчү-папкалары “Җиңү алып килде май!”<br>2. “Геройлар аллеясына” экскурсия<br>3. “Без тынычлык телибез!” рәсем конкурсы<br>4. Ата-аналар җыелышы “2022-2023 нче уку елында белем һәм тәрбия эшчәнлегенең сыйфаты һәм нәтиҗәсе” |

## *III. Программаның оештыру бүлеге*

### *3.1. Төркемнең рухи үсеш мохите һәм материаль яктан тәэмин ителүе*

Баланың яшь үзенчәлеге принцибына таянып эшләргә тырыштык, шул яшьтәге кызыксынуларын исәпкә алдык. Оештырылган предметлы-үстерелешле мохит балаларда шатлык хисе, балалар бакчасына карата эмоциональ уңай караш, бакчага йөрү теләген арттыра, яңа белемнәр тупларга ярдәм итә, танып-белүләрен, актив иҗади сәләтләрен үстерер дип ышанабыз.

Барлык эксплуатацияләнүче бүлмәләр Санпин, хезмәт саклау, янгын сүндерү иминлеге, антитеррористик иминлек таләпләренә туры килә.

***Җиһазлау.***

Төркем бүлмәсе:

- практик эшчәнлек өчен яракланган балалар җиһазлары;
- китап почмагы (яшь үзенчәлекләренә туры килгән китаплар, әкиятләргә иллюстрацияләр, пазл уеннары , “Әкият буйлап сәяхәт”, “Әкиятне җый”, “Әкиятне танып әйт” уены, язучылар портретлары);

- тасвирлау эшчәнлеге өчен почмак (кәгазьләр, карандашлар, пластилин, балчык, трафаретлар, мөһерләр, калыплар, буяулар, гуашь, балавыз акбурлары, кайчылар, пумалалар, бизәү үрнәкләре, тозлы камыр, яраксыз материаллар, сәнгать жанрларының үрнәкләре рәсемнәре һ.б.;
- уен җиһазлары, с/р уеннар ( “Гаилә”, “Без хәрбиләр”, “Янгын сүндерүчеләр”, “Шифаханә”, “Төзелеш”, “Сату үзәге”, “Мода йорты”,”Матурлык үзәге”) уеннарга атрибутлар;
- театр эшчәнлеге почмагы (театр төрләре папкасы; “Әкиятне танып әйт” д/у, өстәл, бармак, шәүләле, кул һ.б театрлар);
- музыкаль эшчәнлек почмагы (музыкаль инструментлар: курай, шөлдерле барабан, барабан, гармун һ.б. музыкаль инструментлар, күргәзмә материаллар, дидактик уеннар, композиторлар портретлары, д/у);
- табигать почмагы (яшелчә, җиләк-җимеш , гөмбә муляжлары, күргәзмә материаллар, дидактик уеннар, өстәл уеннары “Балык кайда качкан?” һ.б.,
- хезмәт почмагы: алъяпкычлар, лейкалар, кечкенә көрәкләр, тырмалар);
- конструкцияләү почмагы (төрле төрдәге конструкторлар: “Лего”, “Агач”, “Зур шакмаклар”,
- кул-бармак эшчәнлеге почмагы (шнуровка, массаж туплары, «Бармаклар» агач тактада ясалган уен, “Энә белән муенса җыябыз” өстәл уеннары; лабиринтлар һ.б) - өстәл, дидиактик, үстерүле уеннар почмагы;
- мини музей почмагы (йорт хайваннары, фантиклар музее);
- “Халкыбызның йолалары” почмагы (күргәзмә материал, балаларның яраксыз әйберләрдән ясалган тарихи манаралары, дидактик уеннар, пазллар);
- кызыклы математика почмагы (Дьенеш блоклары, Киюзенер таякчыклары)
- туган тел почмагы (Г.Тукай портреты, аның әсәрләре җыентыгы, әсәрләр буенча ясалган д/у, татар халкының кул эше үрнәкләре, татар халкының милли әкиятләре һ.б.);
- сд-проигрыватель, сд язмалар (әкиятләр, җырлар, бию көйләре, кул-бармак моторикасы гимнастикасы язмалары һ.б)
-Киенү - чишенү бүлмәсе.
- физкультура почмагы (яшь үзенчәлекләренә яракланган материал: х/у маскалар, туплар, кыршаулар, кульяулыклар, ленталар, обручлар, сикергечләр һ.б., күргәзмә папкалар, уеннар фотоархивы):
- әти-әниләр өчен информацион - күргәзмә почмагы (“Безнең тормыш”, “Меню”, “Котлыйбыз”, “Көндәлек режим”, “ Белем бирү эшчәнлегенең челтәре”, “Табигать үзенчәлекләре”, “Сезнең өчен әти- әниләр”, “Белдерүләр”);
- сәламәтләндерү почмагы (чыныктыру һәм үз-үзеңә массаж ясау җиһазлары, массажерлар, кабыргалы такталар, пробка, төймә келәмчекләре һ.б., күргәзмә информацион материаллар булдырылды

### *3.2. Методик яктан тәэмин ителүе*

| ***Программа һәм методик кулланмалар*** | ***Кем тарафыннан төзелгән, төзүчеләре һәм елы*** |
|---|---|
| Комплексная программа «От рождения до школы» | Комплексно-тематическое планирование по программе «От рождения до школы» под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Подгот. группа Волгоград: Учитель, 2015. |
| | Перспективное планирование воспитательно-образовательного процесса по программе «От рождения до школы» под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Под.группа Волгоград: Учитель, 2013. |

| | |
|---|---|
| | Комплексные занятия по программе «От рождения до школы» под редакцией Н.Е. Вераксы, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. Старшая группа / авт – сост. Ефанова З.А. – Волгоград: Учитель, |
| | Н.Г. Гарипова, Р.С.Әхмәтова ”Әйләнә-тирә дөнья белән таныштыру”. Казан 2016 ел |
| | И.А.Помораева, В.А.Позина Формирование элементарных математиеских представлений. Средняя группа Мозаика-Синтез 2016 |
| | О.А.Соломенникова Ознакомление с природой в детском саду. Средняя группа.Мозаика-Синтез Москва 2016 |
| | Р.М. Зиннәтова ”Сурәтләү һәм кору эшчәнлеге” Казан 2016ел |
| | З.Г.Шәрәфетдинова, Ф.В.Хәзрәтова «Математикага өйрәнәбез» Казан 2016 |
| «Гаиләдә, балалар бакчасында әдәплелек тәрбияләү программасы» | К.В. Закирова, Р.А. Низамов, Мәгариф-2006,<br>“Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы”, Р.К.Шаехова, 2012 |
| | Книга для чтения в детском саду и дома: 2-4года: Пособие для воспитателей и родителей / Сост. В.В. Гербова и др. – М.: Издательство Оникс, 2011. – 272с. |
| Методик кулланма | Кравченко И.В., Долгова Т.Л. Прогулки в детском саду. Младшая и средняя группа. |
| Методик кулланма “ Туган телдә сөйләшәбез | “Туган телдә сөйләшәбез”, З.М.Зарипова. 4-5 яшьлек балалар өчен) - Казан, 2012; |
| Методик кулланма «Табигатьтә кунакта» | Ә.Х. Габдрахимова, Яр Чаллы - 2013 |
| Региональ программа | Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү (программаның милли-төбәк юнәлеше. – Казан, 2014, авторлар: К.В. Закирова, Р.А. Борһанова, һ.б. |
| Тәрбиячеләр өчен кулланма | Борханова Р.А. “Туган як табигате белән таныштыру” Казан, 1997 ел |
| “Әхлак нигезе-матур | К.В.Закирова,Р.Ә.Кадыйрова,Мәгариф,2 004 |
| Балалар бакчасы тәр биячеләре һәм әти-әни ләр өчен хрестоматия “Балачак аланы” | Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти- әниләр өчен хрестоматия. — Казан: РИЦ, 2011. — 560 б.<br>Төзүчесе — Закирова Кафия Вәлиевна |
| “Иң татлы тел – туган тел” | М.Ф.Кашапова “Иң татлы тел – туган тел” 153 бит |
| “Күңел ачыйк бергәләп” Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм музыка җитәкче- | Казан: Мәгариф, 2003, - 303 бит |

ләре өчен ярдәмлек»

### *3.3. Уртанчылар төркемендә көндәлек режим*

**9 нчы уртанчылар төркеменең (4-5 яшь)**
**2022-2023 нчы уку елына көндәлек режимы**

| | | |
|---|---|---|
| 6.00 – 6.30 | Балаларны кабул итү, иртәнге фильтр, мөстәкыйль уеннар. | |
| 6.30 – 7.30 | Саф һавага чыгу (уеннар, күзәтүләр, шәхси эш, хезмәт) | |
| 7.30 – 7.50 | Саф һавадан керү, гигиена процедуралары, гимнастикага әзерлек | |
| 7.50 - 8.00 | Иртәнге гимнастика | |
| 8.00 - 8.20 | Мөстәкыйль эшчәнлек, гигиена процедуралары, иртәнге ашка әзерлек | |
| 8.20 -8.40 | Иртәнге аш | |
| **Дүшәмбе,<br>Пәнҗешәмбе<br>Җомга** | 8.40 – 8.45<br>8.45 – 9.05<br>9.05 – 9.15<br>9.15 – 9.35 | Оештырылган белем эшчәнлегенә әзерлек<br>Оештырылган белем эшчәнлеге<br>Оештырылган белем эшчәнлегенә әзерлек<br>Оештырылган белем эшчәнлеге |
| **Сишәмбе** | 8.40 – 8.45<br>8.45 – 9.05<br>9.05 – 9.35<br>11.15 -11.35 | Оештырылган белем эшчәнлегенә әзерлек<br>Оештырылган белем эшчәнлеге<br>Уеннар, мөстәкыйль эшчәнлек<br>Оештырылган белем эшчәнлеге (ФК саф һавада) |
| **Чәршәмбе** | 8.40 -10.25<br><br>10.25 -10.45<br>10.45 -11.05<br>11.05 -11.15<br>11.15 -11.35<br>11.35 – 11.50 | Саф һавага чыгарга әзерлек, саф һавада булу(уеннар, күзәтүләр,шәхси эш, хезмәт)<br>Саф һавадан керү, гигиена процедуралары,ОББЭ әзерлек<br>Оештырылган белем эшчәнлеге<br>Оештырылган белем эшчәнлегенә әзерлек<br>Оештырылган белем эшчәнлеге<br>Гигиена процедуралары,көндезге ашка әзерлек |
| 9.35 - 9.40 | Икенче иртәнге ашка әзерлек | |
| 9.40 – 9.50 | Икенче иртәнге аш | |
| 9.50 – 11.35 | Саф һавага чыгарга әзерлек, саф һавада булу(уеннар, күзәтүләр,шәхси эш, хезмәт) | |
| 11.35 -11.50 | Саф һавадан керү, гигиена процедуралары,көндезге ашка әзерлек | |
| 11.50 – 12.20 | Көндезге аш | |
| 12.20 -12.30 | Көндезге йокыга әзерлек | |
| 12.30 -15.00 | Көндезге йокы | |
| 15.00 – 15.15 | Акрынлап йокыдан уяну,сәламәтләндерү чаралары | |
| 15.15 – 15.30 | Җиңелчә ашка әзерлек, җиңелчә аш | |
| 15.30 – 16.10 | Уеннар, мөстәкыйль эшчәнлек,индивидуаль һәм коррекцион эшчәнлек, матур әдәбият уку | |
| 16.10 – 16.20 | Кичке ашка әзерлек | |
| 16.20 – 16.40 | Кичке аш | |
| 16.40 – 18.00 | Саф һавага чыгарга әзерлек, саф һавага чыгу,уеннар, балаларны озату | |

### *3.4 Белем бирү эшчәнлеге челтәре*

**2022-2023 уку елына**
**9 нчы уртанчылар төркеменең (4-5 яшь)**
**оештырылган белем бирү эшчәнлеге челтәре**

| | |
|---|---|
| Дүшәмбе | 1. Физик культура 8.45-9.05<br>2. Рәсем 9.15 – 9.35 |
| Сишәмбе | 1. Танып белү (ФЭМП) 8.45 - 9.05<br>2. Физик культура (саф һавада) 11.15-11.35 |
| Чәршәмбе | 1. Сөйләм телен үстерү 10.45-11.05<br>2. Музыка 11.15-11.35 |
| Пәнҗешәмбе | 1. Физик культура 8.45 - 9.05<br>2. Сөйләм телен үстерү 9.15 - 9.35 |
| Җомга | 1. Музыка 8.45 - 9.05<br>2. Әвәләү/кисеп ябыштыру 9.15 - 9.35 |

**3.5.** ***Программа үтәлешен йомгаклау нәтиҗәләре***

***Физик тәрбия***

Төп хәрәкәтләрнең барлык төрләрен дөрес башкара. Спорт элементлары кергән уеннарда актив уйный. Гәүдәне төз, дөрес тота. Статик һәм динамик тигезлекне саклау күнегүләре башкара.Чаңгыда шуа, тауга менә һәм төшә, төшкәндә туктап кала белә. Спорт уеннары элементлары кергән күнегүләр башкара.

***Сәламәтлек***

Культура - гигиена күнекмәләрен өйрәнү (кул, битне мөстәкыйль рәвештә чиста итеп юу, сабын, тарактан дөрес итеп файдалану, юынганнан соң сөртенү, сөлгене урынына элеп кую, кирәк булганда кулъяулыктан файдалану, тешләрне чистарту). Ашау күнекмәләрен үтәү ( азыкны вакламыйча, түкми-чәчми ашау, ашаганда авызны чәпелдәтмәү) кашык, чәнечке, салфеткадан дөрес файдалану.

***Социальләштерү***

Мөстәкыйль рәвештә уеннар оештыра. Берничә рольдән торган һәм тәрбияче катнашында барган уеннарда берләшә, рольләрне бүлә, уен хәрәкәтләрен башкара, уенның төп максатын истә тотып эш итә. Дидактик уеннарда иптәшләре белән киңәшләшә белә. Предметларны тышкы билгеләренә карап чагыштыра, төркемли белә. Уеннар вакытында игътибарлы, күзәтүчән.Төрле сәнгати чаралар( интонация, мимика) файдаланып, таныш әдәби сюжетлар буенча катлаулы булмаган тамаша уйнауда катнаша.Сәхнәләштерелгән уеннарда образлы уенчыклардан файдалана белә.

***Хезмәт***

Мөстәкыйль киенә, чишенә белә. Ашханәдә, табигать почмагында дежурлык бурычларын мөстәкыйль үти. Тәрбиячегә мәйданчыкта чуп-чарны җыярга, веранданы себерергә, кышын кар көрәргә ярдәм итә.

***Тормыш иминлеге***

Балалар бакчасында үз-үзен тоту кагыйдәләрен үти. Юлда, урамда, транспортта үзен тоту кагыйдәләре турында белә.Светофор төсләренең мәгънәсен аңлый,"Җәяүлеләр юлны аркылы чыгу урыны", "Сак булыгыз - балалар!" дигән юл билгеләрен белә.Транспорт төрләре, өлешләре турында; шофер хезмәте турында белә.

Тәбигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен (үсемлек һәм хайваннарга карата  сак, кайгыртучан мөнәсәбәт, куакларны сындырмау, чәчкәләрне өзмәү, чуп - чар ташламау) белү һәм үти.

***Танып белү. Конструкцияләү.***

Предметларның конструкциясен күрә һәм аның гамәли кулланылышын исәпкә алып анализлый.

Кулланылышына карап, предметларның төрле конструкцияләрен төзи.

Пластмасса һәм агач конструкторлардан рәсемгә карап һәм сүз белән аңлату буенча модельләр төзи.

***Иң гади математик күзаллауларын үстерү***

Предметларны төркемли, төркемнән аерым өлешләрен ала белә. 10 кга кадәр  һәм аннан артыграк санау, тәртип буенча санау ( 20 саны эчендә.)Алу һәм кушуга бер гамәлле мәсьәләләр төзи һәм чишә, цифрлар һәм арифметик тамгалар куллана белә. Предметларны ике һәм дүрт тигез кисәккә бүлә. Бөтен предметны һәм аның өлешләрен чагыштыра белә.Предметларны формасы буенча чагыштыра, таныш фигураларны чынбарлыктагы предметларны күрә белә. Сәгатькә карап вакытны билгели белә.

***Әйләнә-тирә белән танышу.***

Экологик бәйләнешләрне аңлата белә, кешенең табигатҗ белән бәйләнеше һәм үзара йогынтысы турында белә. Табигатьне сакларга, яратырга кирәклеген белә.

***Аралашу. Сөйләм телен үстерү.***

Күмәк сөйләшүдә катнаша, сораулар бирә, вакыйгалар, фактлар, күренешләр турында эзлекле итеп сөйли белә. Сөйләмдә синонимнар, антонимнар, кушма җөмләләр куллана."Аваз", "иҗек", "сүз", "җөмлә" төшенчәләрен аерып әйтә белә. Җөмләдә башка сүзләрне , ә аннары сүздәге авазларны, иҗекләрне әйтә белә. Җөмләдә бирелгән аваз кергән сүзләр эзләп таба, сүздә авазның урынын билгели белә.

Зур булмаган әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү, сәхнәләштерә, алдан төзелгән план һәм тәрбияче үрнәге буенча үз тәҗрибәсеннән чыгып предметлар, сюҗетлы рәсемнәр турында рәсемнәр җыелмасы буенча сөйли белә.

***Матур әдәбият белән танышу***

Әдәби әсәрләрне ңанры буенча танып әйтә белә, җавабын дәлилли белә.Яраткан әкият һәм хикәяләрне атый белә, 1-2 яраткан шигырь, 2-3 санамышны яттан сөйли, 2-3 табышмак әйтэ.2-3 балалар китабы авторын, 2-3 китап иллюстраторын белә. Сәнгатьле итеп шигырь сөйли, әкият, пьесаның эчтәлеген сөйли.

***Сынлы сәнгать. Рәсем***.

Әйләнә-тирә тормыш, әдәби әсәрләр темасына шәхси һәм күмәк рәсемнәр, декоратив, предметлы һәм сюжетлы композицияләр тудыра ала. Рәсем ясаганда төрле материаллар һәм сурәтләүнең төрле ысулларын куллана белә.

***Әвәләү***

Фигураларның торыш һәм хәрәкәтләрен, предметларның формасын биреп, төрле әйберләр әвәли беләләр. Әвәләп ясалган әйберләрне халык сәнгате мотивлары буенча бизи ала .

***Кисеп ябыштыру***

Төрле фактуралы кәгазь һәм балалар элек үзләштергән кисү һәм ерткалау алымнарын кулланып, төрле предметларның сурәтләрен барлыкка китерү, сюцетлы һәм декоратив композицияләр иҗат итү.

***Музыка***

Россия Федерациясенең дәүләт гимнын таный белә.Тыңлаган әсәр кайсы жанрга (марш, җыр, бию) туры килүен һәм нинди музыка уен коралында башкарылганын белә. Әсәрнең кисәкләрен (кереш, тәмамлау өлеше, җыр башы, кушымта) аера белә. Әсәрнең эчтәлеген аңлый , тасвирлау чараларын ишетә белә. Көйнең гомуми юнәлешен һәм аерым кисәкләрен музыка уен коралына кушылып дөрес җырлый белә.Төрле характердагы музыка әсәрләренең характерына, музыкаль образларга туры китереп, ритмик хәрәкәтләр ясый белә.Уен җырларын сәхнәләштерә, түгәрәк һәм башка төр уеннарда образлы хәрәкәтләрнең төрле вариантларын уйлап таба белә.

## ***IV. Кушымта***

### ***4.1. Балалар бакчасында балаларны сәламәтләндерү эше.***

***Бурычлар:***

- Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, физик үсешләрен камилләштерү, организмнарының каршы торучанлыгын һәм саклау үзенчәлекләрен күтәрү, физик һәм акыл эшчәнлеген яхшырту, чыныктыру, балаларны сәламәтләндерү.
- Балаларда тормыш өчен мөһим булган хәрәкәт күнекмәләре формалаштыру, физик әзерлек нең билгеле бер баскычына җитү;
- Балаларда шәхси культура тәрбияләү, физик камиллеккә омтылыш тәрбияләүне формалаш тыру, аларда белем күнекмәләре тәрбияләү;

Шушы бурычларны тормышка ашыру өчен балалар бакчасында түбәндәге шартлар тудырылган:

- Ябык һәм ачык спорт мәйданчыгы;
- Массаж; (өлешчә)

***Балаларның физик сәламәтлеге түбәндәге чаралар белән ныгытыла:***

- Балаларны рациональ тукландыру
- Чыныктыру процедуралары
- Хәрәкәтләрне үстерү
- Режим гигиенасы

***Туклануны оештыру принциплары:***

- Туклану режимының үтәлеше
- Туклануның калориялелеге, кирәкле норманың даими сакланышы
- Азык кабул итү гигиенасы,якын килү
- Җиһазларның дөрес сайланышы

***Чыныктыру процедуралары:***

- Чыныктыру көндәлек режимның һәр элементына яраклаша
- Чыныктыру төрле хәрәкәт активлыгы фонында булдырыла
- Уңай эмоциональ фонда һәр бала организмның җылылык комфорты булганда

үткәрелә

***Балалар бакчасында киң чыныктыру комплексы алып барыла:***

- Җиңелчә кием.
- Балаларның индивидуаль сәламәтлек торышына карап , саф һава вакытында
- Сезонга карап киенүне булдыру.
- Көнлек температура режимын саклау.
- Йокыдан соң сулыш алу гимнастикасы.
- Салкынча су белән терсәккә кадәр кулларны, битне юу.
- Яланаяк спортзалда йөгерү.
- Сырлы тактадан, төймәле тукымадан ялан аяк йөрү.
- Саф һавада йөрү һәм аның вакытын дөрес оештыру;
- Авыз куышлыгын һәм тамак төбен чайкау, (тозлы су белән)

***Физик тәрбияне оештыру формалары:***

Физкультура шөгыльләре.

Спорт уеннары.

***4.2 Уяну гимнастикасы буенча комплекс – тематик план***

| ***ай*** | ***гимнастика*** |
|---|---|
| ***сентябрь*** | «Уяну»<br>Йокы качты тәрәзәдән, йөгерде юллардан,<br>Ә без синен белән уяндык, уяндык та елмайдык (киерелү)<br>Башта күзләрнен берсен ачтык, аннары икенчесен,<br>Кулларны күтәреп төшердек, велосипед әйләндердек.<br>Уңга-сулга борылдык, аннары сикереп тордык. |
| ***октябрь*** | «Хәерле иртә»<br>Хәерле иртә, күзләр. Сез уяндыгызмы?(күзләргә массаж. Бармаклар белән бинокль ясап, як-якка карыйлар)<br>Хәерле иртә, колаклар. Сез уяндыгызмы?(колакларга массаж. Учны колакларга куялар (“Чебурашка”), як-якны тыңлыйлар)<br>Хәерле иртә, куллар. Сез уяндыгызмы?(кулларның башта берсенә, аннан икенчесенә массаж. “Пропеллер” күнегүе)<br>Хәерле иртә, аяклар. Сез уяндыгызмы?( аякларның башта берсенә, аннан икенчесенә массаж. “Велосипед” күнегүе)<br>Хәерле иртә, кояш. Мин уяндым!( кулларны сузып киерелү) |
| ***ноябрь*** | Әйдәгез, бергәләп, басабыз,<br>Кулларны ян – якка сузабыз.<br>Аннары бөгеләбез,бергәләп тураябыз.<br>Кулларны күтәрәбез,<br>Кояшка сәләм юллыйбыз.<br>Кулларны качырабыз,<br>Аннары аларны бергәләп эзлибез.<br>Уңга карыйк,<br>Сулга борылыйк.<br>Утырабыз, торабыз.<br>Үкчәгә дә басыбыз,<br>Аяк очларына басып,<br>Кояшка үреләбез. |
| ***декабрь*** | «Без шулай итәбез»<br>Без йоклап тордык, бераз уйнарга булдык.<br>Башны иябез алга, уңга, сулга борабыз,<br>Аннан карап торабыз.<br>Иң өсләрен сикертәбез, кулларны биетәбез. |

| | |
|---|---|
| | Бер алга, бер артка сузып,<br>Күңелле ял итәбез.<br>Аннары без чүгәлибез, тезләрне кочаклыйбыз.<br>Башны алга яшереп, без ападан качабыз. |
| ***январь*** | «Пескәй »<br>1. “Пескәй уяна”.  Ятып, бергә уң аякны һәм сул кулны күтәрәләр, төшерәләр. Аннан сул аякны һәм уң кулны күтәрәләр, төшерәләр. Аннан 2 кулны һәм 2 аякны бергә күтәрәләр, төшерәләр. 4-5 тапкыр кабатларга.<br>2. «Пескәй сөенә». Үрмәләү позасына керергә. Башны күтәрергә, умыртка сөяген бөгәргә. Тирән сулыш алырга. 4-5 тапкыр кабатларга.<br>3.«Пескәй ачулана ». Үрмәләү позасына керергә. Иякне күкрәккә тидерергә, арканы бөгәргә. Тирән сулыш алырга. 4-5 тапкыр кабатларга.<br>4. “Пескәй сузыла”  Сузылу күнегүе.<br>5. “Пескәй сикерә” Сикерү. |
| ***февраль*** | “Чәчәк”<br>Чәчәк йоклый,<br>Чәчәк уяна. (киерелү күнегүләре)<br>Иртәнге кояшка<br>Ул бик куана. (урында сикерү)<br>Кояшка сузыла (аяк очларына басып, сузылалар)<br>Кояшка үрелә (аяк очларына басып, сузылалар)<br>Күбәләк дустына (кулларны канатлар каккан кебек җилпиләр)<br>Сәлам өләшә (сәлам бирәләр) |
| ***март*** | Без уяндык, (киерелү күнегүләре)<br>Күзләрне ачтык, (күзләрен ачалар)<br>Аякларны суздык (аякларын сузып, селкетәләр)<br>Аларны да уяттык!<br>Ян –якка борылып (басып, ян –якка борылалар)<br>Кояшка без карадык. (аяк очларына басып, сузылалар)<br>Якты көнгә сокланып,<br>Матур итеп елмайдык. (ян – якка борылып, елмаялар)<br>Сикереп тә алдык (сикерү күнегүләре)<br>Йөгердек тә (урында йөгерү)<br>Хәзер инде без<br>Уйнарга бергә әзер! (үз-үзеңне кочу) |
| ***апрель*** | Аякларың тыпырдат (аякларны тыпырдаталар)<br>Кулларыңны чәбәклә.(кулларны чәбәклиләр)<br>Бер монда, бер монда,<br>Кыен эш түгел бер дә. (ян-якка борылып кулларны чәбәклиләр)<br>Башың аска иеп ал, (башларын бер иеп, бер күтәрәләр)<br>Кулларыңны болгап ал. (йөзү күнегүләре)<br>Бер монда, бер монда,<br>Кулларыңны болгап ал.(ян- якка борылып, йөзү күнегүләре эшлиләр)<br>Бу дустың белән күреш, (уңга борылып, сәләм юллыйлар, елмаялар)<br>Бу дустың белән күреш.(сулга борылып, сәләм юллыйлар, елмаялар)<br>Йә иптәш, йә, әйлән, (урында сикереп, әйләнәләр)<br>Бик кыен түгел бу эш. |
| ***май*** | Нәниләр бара тигез юл буйлап. (урында атлыйлар)<br>Тигез юл буйлап, ашыкмый атлап. (урында атлыйлар)<br>Зур-зур ташларны<br>Сикереп үтәләр. (урында сикерәләр)<br>Уңга да баралар, сулга да баралар, (уңга – сулга борылу күнегүләре)<br>Су аша йөзеп, (йөзү күнегүләре) |

| | |
|---|---|
| | ярга чыгалар. (сулыш алу күнегәләре) |

### *4.3 Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү буенча комплекс - тематик план.*

| *№* | *темасы* | *максаты* | *ае* |
|---|---|---|---|
| 1. | Уен – шөгыль.“Кем ераграк сикерә?”, ”Кем капчыкны ераграк ыргыта?” | Балаларны пространство да ориентлашырга өйрәтү,сөйләм күнекмәләрен үстерү, “ерак – якын”, “монда”, “тегендә” төшенчәләрен анлату. | сентябрь |
| 2. | Территория буенча прогулка.Уен:”Куянны табыйк”. | Балаларга “анда”, “монда”,“аста”,”өстә” төшенчәләрен аңлату, дус – тату уйнауларына ирешү. | |
| 3. | Уен: “Минем янга йөгерегез”. | Балаларны сигнал буенча бер – берсенә бәрелмичә йөгерергә өйрәтү. | |
| 4. | Рәсем ясау. | Балаларга йомгакларны аста, өстә, кырда, зур, кечкенә итеп ясарга өйрәтү. | |
| 5 | Урам белән танышу . Хәрәкәтле уен “Чып-чыклар һәм машина” | Урам һәм анда үзеңне тоту кагыйдәләре ту-рында башлангыч күзалалуларны үстерү .Ба-лалаың урам ,юл,тротуар,йөк һәм җиңел ма-шиналар турындагы күзаллауларын төгәл билгеләү.Хәтер һәм бәйләнешле сөйләм үстерү. | октябрь |
| 6. | Дидактик уен “Автобусны ясап бетер” | Хыял,күз алдына китерүне үстерү.<br>Уен эчтәлеге:башлаган автобус рәсемен ясап бетерергә. | |
| 7. | Трансрпорт төрләре. | Балаларны транспорт төрләре белән та-ныштыру,аларда игътибарлылык ,ярдәмчел-лек ,хәлгә керә белү сыйфатлары тәрбияләү | |
| 8. | Шәһәр транспорты белән танышу:трам-вай һәм троллейбус. д/уен “Светофор” | Автобус һәм аның өлешләре белән танышу, пассажир турында башлангыч мәгълүмат бирү велосипед йөртү күнекмәләрен үстерү,машина йөртүчегә ихтирам тәрбияләү. | |
| 9. | Дидактик уен”Автомо-бильне төзәт”. | Күрсәтмә-гамәлле фикерләүне,игътибарны,төп детальләрне аерып күрсәтү күнекмә-ләрен үстерү,күрү ,игътибарын үстерү. | ноябрь |
| 10. | Автобус белән танышу. | Балаларны җәмәгать транспортында үзлә-рен тоту кагыйдәләре белән таныштыру;транспорт чарасы буларак “автобус”тө-шенчәсе б/н таныштыру,”пассажир”,”транспорт йөртүче” төшенчәләрен аңла-ту.Игъти- бар белән хәтерне,сорауларга җавап бирү күнекмәләрен үстерү. | |
| 11. | Уен.”Төсле автобуслар” | Төсләрне, формаларны аера һәм чагыштыра белергә өйрәтү, автобуста үз – үзеңне тота белү күнекмәләрен үстерү. | |
| 12. | Кисеп ябыштыру шөгыле: “Төрле төстәге түгәрәкләр | Предметларны төсләре һәм формалары буенча аера белергә өйрәтү. | |
| 13. | ”Йөк һәм маршрут буенча | Транспорт төрләре турындагы белемнәрне формалаштыруны дәвам итү. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | йөрүче тран-спорт чаралары” | | |
| 14. | Шәһәр урамы. | Балаларны шәһәр урамы һәм аның төп өлешләре белән таныштыру. | |
| 15. | Җәяүлеләр һәм пасса-жирлар өчен кагый-дәләр. | Җәяәүлелеәр өчен булган кагыйдәләр б\н таныштыруны дәвам итү. | |
| 16. | Экскурсия “Авыл урамнарыда транспорт хәрәкәтен күзәтү”. | Балаларны юл йөрү кагыйдәләре белән та-ныштыруны дәвам итү,урамда дөрес йөрергә өйрәтү;җәяүлелеәр өчен булган кагыйдәләрне өйрәнү. | |
| 17. | Төсләр иленә сәяхәт. | Юлларда  үзеңне хәвефсез тоту күнекмәләрен үстерү. | январь |
| 18. | Хәрәкәтле уен “Миңа таба йөгерегез”уйнау.. | Ишетү игътибарын үстерү. | |
| 19. | Дидактик  уен “Кыен виражлар”. | Бармаклар   хәрәкәтләнүен ,игътибарны,ике үлчәүле киңлектә (кәгазь битләрендә )ори-ентлашуны үстерү. | |
| 20. | Транспорт төрләре сүрәтләнгән рәсемнәр карау. | Балаларны трапспорт  төрләрен  аера белергә өйрәтү. | Февраль |
| 21. | Шундый төрле машиналар. | Юл хәрәкәтендә машиналарны аера белү күнекмәләрен формалаштыру. | |
| 22. | Үстерешле уен “Тапкыр җәяүле” | Эзләнүле фикерләүне үстерү. Игътибарлылык,күзәтүчәнлек тәрбияләү. | |
| 23. | Трамвай һәм троллей-бус белән таныштыру. | Балаларны яңа транспорт төрләре-трамвай, троллейбус белән таныштыру,аларның башка транспорттан аермалы якларын аңлату. | |
| 24. | Светофорны күзәтү. | Светофор сигналларын өрәнү. | март |
| 25. | Светофор. | Балалрны светофор төсләрен ерырга,тәрбияче күрсәткән төскә туры китереп хәрәкәт итәргә өйрәтү.Игътибарлылык,күзәтүчәнлек тәрбияләү. | |
| 26. | Үстерешле уен “Дөрес светофорны эзләп тап” | Балаларның сенсор сәләтләрен,предменың төс һәм формаларын тану һәм әйтеп бирү күнекмәлә- рен үстерү,светофор сигналларының мәгънәлә-рен аңлауларын ныгыту. | |
| 27. | “Светофорның төслә-ре “хәрәкәтле уенын уй-нау. | Балаларның светофорның вазифасы һәм сигнал-лары турындагы күзаллауларын ныгыту.төсләр турындагы күзаллауларын ныгыту. | |
| 28. | Транспорт төрләре һәм аларның аермалыклары | Балаларны транспорт төрләрен аерырга өйрәтү. | апрель |
| 29. | Үстерешле уен “Кем нәрсәдә бара” | Уен вакытында кулның ирекле хәрәкәтләрен һәм күрү-хәрәкәт итү координациясен үстерү.Бала- ларның транспортта үзләрен тоту кагыйдәләре турындагы белемнәрен киңәйтү.Транспорт төр-ләрен аеру күнекмәләрен ныгыту. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 30. | “Атлар” хәрәкәтле уенын уйнау. | Җигүле транспорт белән таныштыру,ишетү игътибарын үстерү. | |
| 31. | Автомашинаны исеңдә калдыр. | Күрү игътибарын үстерү. | |
| 32. | “Безнең урамыбыз”. | Ике үлчәмле киңлектә ориентлашуны үстерү, рольләрне башкару күнекмәләрен формалашты-ру,балаларның пассив һәм актив сүзләрен баету. | май |
| 33. | “Үз төсеңне эзләп тап” хәрәкәтле уенын уйнау. | Бүлмә эчендә җиңел ориентлашу күнекмәсен ка-милләштерү,ишетү игътибарын үстерү,төп төсләрне кабатлау. | |
| 34. | Транспорт төрләре турында табышмаклар әйтү.Юл макетын кулланып машиналар белән уйнау. | Балаларның транспорт төрләре турындагы белемнәрен ачыклау.Балаларга юл йөрү кагый -дәләрен өйрәтүне дәвам итү. | |
| 35. | Якындагы урамга экскурсия | Юл хәрәкәте, тротуар, машиналар турындагы белемнәрен тулыландыру. | |
| 36. | Йомгаклау дәресе:”без барабызґ.барабыз, бара- быз” | Балаларның транспорт төрләре турындагы белемнәрен ныгыту;әйләнә-тирә мохиткә кызыксыну тәрбияләү. | |

Прошнуровано, пронумеровано
32 (тридцать два)
листа
Заведующий МБДОУ «Детский сад комбинированного вида №76 «Ветерок»
Т.В. Мартьянова

«Ветерок»
ИНН 1650086670